| | өч яшьтән артыграк | шәһәр | 24926 | 32054 | 39182 | 46310 | 60431 | 69723 | 76693 | 83662 | 92955 | 79016 | 85985 | 95278 | 106894 | 106894 |
| | | авыл | 26567 | 34214 | 41862 | 49509 | 64645 | 74614 | 82090 | 89567 | 99536 | 84583 | 92059 | 102028 | 114489 | 114489 |
| Интеллекты бозылган балалар (акылга зәгыйфьләр) | өч яшькә кадәр | шәһәр | 37400 | 48508 | 61938 | 73043 | 95705 | 111967 | 123583 | 135199 | 228124 | 125906 | 139845 | 153784 | 172369 | 265294 |
| | | авыл | 40033 | 51948 | 66357 | 78272 | 102570 | 120016 | 132477 | 144938 | 244628 | 134969 | 149923 | 164876 | 184814 | 284504 |
| | өч яшьтән артыграк | шәһәр | 24926 | 32054 | 39182 | 46310 | 60431 | 69723 | 76693 | 83662 | 92955 | 79016 | 85985 | 95278 | 106894 | 106894 |
| | | авыл | 26567 | 34214 | 41862 | 49509 | 64645 | 74614 | 82090 | 89567 | 99536 | 84583 | 92059 | 102028 | 114489 | 114489 |

| Тәрбияләнүчеләр категориясе | Тәрбияләнүчеләрнең яшь ягыннан составы | Җирлек (округ) | Мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында мәктәпкәчә белемнең җайлаштырылган уку-укыту программаларын гамәлгә ашыруга финанс чыгымнары нормативы, елына сумнарда/бер тәрбияләнүчегә | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | биш көнлек эш атнасы | | | | | | | | | алты көнлек эш атнасы | | | | |
| | | | көненә эш сәгатьләре саны | | | | | | | | | көненә эш сәгатьләре саны | | | | |
| | | | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 9 | 10,5 | 12 | 24 | 9 | 10,5 | 12 | 14 | 24 |
| Ишетү сәләте бозылган балалар (ишетмәүчеләр) | өч яшькә кадәр | шәһәр | 37400 | 48508 | 61938 | 73043 | 95705 | 111967 | 123583 | 135199 | 228124 | 125906 | 139845 | 153784 | 172369 | 265294 |
| | | авыл | 40033 | 51948 | 66357 | 78272 | 102570 | 120016 | 132477 | 144938 | 244628 | 134969 | 149923 | 164876 | 184814 | 284504 |
| | өч яшьтән артыграк | шәһәр | 39184 | 50291 | 63722 | 74827 | 97489 | 113751 | 125367 | 136983 | 153244 | 127690 | 141629 | 155568 | 174153 | 174153 |
| | | авыл | 41864 | 53779 | 68188 | 80103 | 104401 | 121846 | 134308 | 146769 | 164215 | 136800 | 151753 | 166707 | 186645 | 186645 |
| Күрү сәләтен югалткан балалар (сукырлар) | өч яшькә кадәр | шәһәр | 37400 | 48508 | 61938 | 73043 | 95705 | 111967 | 123583 | 135199 | 228124 | 125906 | 139845 | 153784 | 172369 | 265294 |
| | | авыл | 40033 | 51948 | 66357 | 78272 | 102570 | 120016 | 132477 | 144938 | 244628 | 134969 | 149923 | 164876 | 184814 | 284504 |
| | өч яшьтән артыграк | шәһәр | 39184 | 50291 | 63722 | 74827 | 97489 | 113751 | 125367 | 136983 | 153244 | 127690 | 141629 | 155568 | 174153 | 174153 |
| | | авыл | 41864 | 53779 | 68188 | 80103 | 104401 | 121846 | 134308 | 146769 | 164215 | 136800 | 151753 | 166707 | 186645 | 186645 |
| Ишетү сәләтен өлешчә югалткан балалар (начар ишетүчеләр) | өч яшькә кадәр | шәһәр | 37400 | 48508 | 61938 | 73043 | 95705 | 111967 | 123583 | 135199 | 228124 | 125906 | 139845 | 153784 | 172369 | 265294 |
| | | авыл | 40033 | 51948 | 66357 | 78272 | 102570 | 120016 | 132477 | 144938 | 244628 | 134969 | 149923 | 164876 | 184814 | 284504 |
| | өч яшьтән артыграк | шәһәр | 31434 | 39182 | 49253 | 57002 | 75777 | 87393 | 94362 | 103655 | 115270 | 96685 | 108301 | 117593 | 131532 | 131532 |
| | | авыл | 33548 | 41862 | 52667 | 60979 | 81108 | 93569 | 101046 | 111015 | 123476 | 103538 | 115999 | 125968 | 140922 | 140922 |

| Тәрбияләнүчеләр категориясе | Тәрбияләнүчеләрнең яшь ягыннан составы | Җирлек (округ) | Мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында мәктәпкәчә белемнең җайлаштырылган уку-укыту программаларын гамәлгә ашыруга финанс чыгымнары нормативы, елына сумнарда/бер тәрбияләнүчегә | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | биш көнлек эш атнасы | | | | | | | | | алты көнлек эш атнасы | | | | |
| | | | көненә эш сәгатьләре саны | | | | | | | | | көненә эш сәгатьләре саны | | | | |
| | | | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 9 | 10,5 | 12 | 24 | 9 | 10,5 | 12 | 14 | 24 |
| Терәк-хәрәкәт аппараты бозылган балалар | өч яшькә кадәр | шәһәр | 37400 | 48508 | 61938 | 73043 | 95705 | 111967 | 123583 | 135199 | 228124 | 125906 | 139845 | 153784 | 172369 | 265294 |
| | | авыл | 40033 | 51948 | 66357 | 78272 | 102570 | 120016 | 132477 | 144938 | 244628 | 134969 | 149923 | 164876 | 184814 | 284504 |
| | өч яшьтән артыграк | шәһәр | 31434 | 39182 | 49253 | 57002 | 75777 | 87393 | 94362 | 103655 | 115270 | 96685 | 108301 | 117593 | 131532 | 131532 |
| | | авыл | 33548 | 41862 | 52667 | 60979 | 81108 | 93569 | 101046 | 111015 | 123476 | 103538 | 115999 | 125968 | 140922 | 140922 |
| Туберкулез интоксикациясе булган балалар | өч яшькә кадәр | шәһәр | 23142 | 30270 | 37398 | 44526 | 58647 | 67940 | 74909 | 81878 | 137633 | 77232 | 84201 | 93494 | 105110 | 160865 |
| | | авыл | 24736 | 32383 | 40031 | 47678 | 62814 | 72783 | 80260 | 87736 | 147550 | 82752 | 90229 | 100198 | 112659 | 172473 |
| | өч яшьтән артыграк | шәһәр | 17799 | 21778 | 28081 | 32058 | 40774 | 47743 | 52389 | 57036 | 64005 | 52389 | 59359 | 64005 | 70974 | 70974 |
| | | авыл | 18923 | 23191 | 29951 | 34220 | 43556 | 51033 | 73463 | 61002 | 68479 | 56017 | 63494 | 68479 | 75955 | 75955 |
| Еш авыручы балалар | өч яшькә кадәр | шәһәр | 23142 | 30270 | 37398 | 44526 | 58647 | 67940 | 74909 | 81878 | 137633 | 77232 | 84201 | 93494 | 105110 | 160865 |
| | | авыл | 24736 | 32383 | 40031 | 47678 | 62814 | 72783 | 80260 | 87736 | 147550 | 82752 | 90229 | 100198 | 112659 | 172473 |
| | өч яшьтән артыграк | шәһәр | 17799 | 21778 | 28081 | 32058 | 40774 | 47743 | 52389 | 57036 | 64005 | 52389 | 59359 | 64005 | 70974 | 70974 |
| | | авыл | 18923 | 23191 | 29951 | 34220 | 43556 | 51033 | 56017 | 61002 | 68479 | 56017 | 63494 | 68479 | 75955 | 75955 |
| Катлаулы дефектлары булган балалар | өч яшькә кадәр | шәһәр | 44526 | 58783 | 63747 | 87296 | 115385 | 133970 | 147909 | 161848 | 273358 | 150232 | 166494 | 185079 | 205987 | 317497 |
| | | авыл | 47678 | 62973 | 78266 | 93561 | 123682 | 143620 | 158574 | 173527 | 293155 | 161066 | 178512 | 198450 | 220880 | 340508 |
| | өч яшьтән артыграк | шәһәр | 46310 | 60567 | 74823 | 89080 | 117169 | 135754 | 149693 | 163632 | 275142 | 152016 | 168278 | 186863 | 207771 | 207771 |
| | | авыл | 49509 | 64804 | 80097 | 95391 | 125513 | 145451 | 160404 | 175358 | 195296 | 162897 | 180342 | 200280 | 222711 | 222711 |

| Тәрбияләнүчеләр категориясе | Тәрбияләнүчеләрнең яшь ягыннан составы | Җирлек (округ) | Мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында мәктәпкәчә белемнең җайлаштырылган уку-укыту программаларын гамәлгә ашыруга финанс чыгымнары нормативы, елына сумнарда/бер тәрбияләнүчегә | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | биш көнлек эш атнасы | | | | | | | | | алты көнлек эш атнасы | | | | |
| | | | көненә эш сәгатьләре саны | | | | | | | | | көненә эш сәгатьләре саны | | | | |
| | | | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 9 | 10,5 | 12 | 24 | 9 | 10,5 | 12 | 14 | 24 |
| Сөйләмендә фонетик-фонематик җитешсезлекләре булган балалар | өч яшьтән артыграк | шәһәр | 21358 | 28073 | 32464 | 39176 | 51742 | 58711 | 65680 | 70327 | 77296 | 65680 | 72650 | 79619 | 88912 | 88912 |
| | | авыл | 22741 | 29943 | 34654 | 41856 | 55323 | 62799 | 70276 | 75261 | 82737 | 70276 | 77753 | 85230 | 95199 | 95199 |
| Сәламәтлек ягыннан башка мөмкинлекләре чикле булган балалар | өч яшькә кадәр | шәһәр | 23142 | 30270 | 37398 | 44526 | 58647 | 67940 | 74909 | 81878 | 137633 | 77232 | 84201 | 93494 | 105110 | 160865 |
| | | авыл | 24736 | 32383 | 40031 | 47678 | 62814 | 72783 | 80260 | 87736 | 147550 | 82752 | 90229 | 100198 | 112659 | 172473 |
| | өч яшьтән артыграк | шәһәр | 17799 | 21778 | 28081 | 32058 | 40774 | 47743 | 52389 | 57036 | 64005 | 52389 | 59359 | 64005 | 70974 | 70974 |
| | | авыл | 18923 | 23191 | 29951 | 34220 | 43556 | 51033 | 56017 | 61002 | 68479 | 56017 | 63494 | 68479 | 75955 | 75955 |

5. Аз комплектлы балалар бакчаларында мәктәпкәчә белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыруга финанс чыгымнары нормативлары

| Мәктәпкәчә мәгариф оешмасының атнага эш көннәре саны | Мәктәпкәчә мәгариф оешмасының эш сәгатьләре саны | Мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында мәктәпкәчә белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыруга финанс чыгымнары нормативы, елына сумнарда/бер төркемгә | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | бер үк яшьтәге төркемнәр | | | төрле яшьтәге төркемнәр | | |
| | | 2 айдан алып 1 яшькә кадәр | 1 яшьтән алып 3 яшькә кадәр | 3 яшьтән алып 7 яшькә кадәр | 2 айдан алып 3 яшькә кадәр | өч төрле яшьтәгеләр: 3 яшьтән алып 7 яшькә кадәр | ике төрле яшьтәгеләр: 3 яшьтән алып 7 яшькә кадәр |
| 5 эш көне | 3 | 59378 | 80451 | 99640 | 63614 | 78575 | 99640 |
| | 4 | 88133 | 102018 | 128395 | 86495 | 107331 | 128395 |
| | 5 | 102511 | 123585 | 128395 | 109623 | 121708 | 128395 |
| | 6 | 116888 | 145151 | 157151 | 121125 | 136086 | 157151 |
| | 7 | 157366 | 157547 | 198847 | 155659 | 176563 | 198847 |
| | 9 | 201342 | 201533 | 228456 | 202513 | 220540 | 228456 |
| | 10,5 | 230098 | 244667 | 257212 | 225517 | 249295 | 257212 |
| | 12 | 258853 | 266233 | 285967 | 260024 | 278051 | 285967 |
| | 24 | 488896 | 503465 | 343478 | 501569 | 306806 | 343478 |
| 6 эш көне | 9 | 230098 | 244667 | 285967 | 237017 | 249295 | 285967 |
| | 10,5 | 273231 | 287800 | 314722 | 271524 | 292429 | 314722 |
| | 12 | 301986 | 309366 | 343478 | 284911 | 321184 | 343478 |
| | 14 | 345119 | 374066 | 400988 | 352039 | 364317 | 400988 |
| | 24 | 589540 | 611298 | 400988 | 593584 | 364317 | 400988 |

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 1147. Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 26 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 17 статьяда:

а) 2 пунктта «үз көченә керә торган Татарстан Республикасы законнары» сүзләреннән соң «чираттагы финанс елына һәм план чорына» сүзләрен өстәргә;

б) 3 пунктта «тәкъдим итә торган үзгәрешләр кертү» сүзләреннән соң «чираттагы финанс елына һәм план чорына» сүзләрен өстәргә;

2) 20 статьяда:

а) 1 пунктта:

икенче абзацта «шул исәптән» сүзләрен «моңа» сүзенә, «ассигнованиеләр» сүзен «ассигнованиеләр дә керә» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «дәүләт (муниципаль) учреждениеләре» сүзләреннән соң «һәм дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләре» сүзләрен өстәргә;

бишенче абзацта «– товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 2 пунктта «хезмәте күрсәтүләргә» сүзләреннән соң «(эшләр башкаруга)» сүзләрен өстәргә;

3) $20^{1}$ статьяда:

а) 1 пунктта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының озак вакытлы максатчан программалары, шулай ук» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт программалары, муниципаль программалар, шулай ук тиешенчә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының,» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 пунктта:

беренче абзацта «һәм аңа туры килә торган чыгымнар төре» сүзләрен төшереп калдырырга;

икенче абзацта «һәм аңа туры килә торган чыгымнар төре» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 4 пунктның икенче абзацында «һәм аңа туры килә торган чыгымнар төре» сүзләрен төшереп калдырырга;

г) 7 пунктның өченче абзацында «һәм әлеге Кодексның 55 статьясы» сүзләрен төшереп калдырырга;

4) $20^2$ статьяда:

а) исемдә «Дәүләт һәм» сүзләрен «Дәүләт яисә» сүзләренә алмаштырырга;

б) «Дәүләт һәм» сүзләрен «Дәүләт яисә» сүзләренә алмаштырырга;

5) 23 статьяның 3 пунктында «һәм Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы, шушы закон белән җирле бюджетларга тиешле субвенцияләрне раслау шарты белән, ел саен гамәлгә кертелергә» сүзләрен төшереп калдырырга;

6) IV бүлек исемендә «каплау» сүзен «финанслау» сүзенә алмаштырырга;

7) 24 статьяда:

а) 2 пунктның икенче абзацында «раслау һәм Татарстан Республикасы бюджеты» сүзләрен «раслау һәм (яисә) Татарстан Республикасы бюджеты» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 пунктның өченче абзацында «раслау һәм җирле бюджет» сүзләрен «раслау һәм (яисә) җирле бюджет» сүзләренә алмаштырырга;

8) 25 статьяда:

а) 1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын исәпкә алу буенча бердәй счетта калган акчалар белән идарә итү буен-

ча операцияләр башкарганда, Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын исәпкә алу буенча бердәй счеттан күчерелгән акчалар һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын исәпкә алу буенча бердәй счетка күчерелгән акчалар арасындагы аерма.»;

б) 3 пунктта:

өченче абзацта «бюджет» сүзен «Татарстан Республикасы бюджеты» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«товарлар ташуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә Татарстан Республикасы исеменнән төзелгән дәүләт контрактлары шартлары нигезендә, Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган очракларда, хисап финанс елында түләнергә тиешле бу дәүләт контрактларын түләүгә бюджет ассигнованиеләренең файдаланылмый калган суммасыннан артмый торган күләмдә күрсәтелгән максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыру өчен җибәреләләр.»;

в) түбәндәге эчтәлекле $3^1$ пункт өстәргә:

«$3^1$. Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын исәпкә алу буенча бердәй счетта калган акчалар белән идарә итү буенча операцияләр составына түбәндәгеләр керә:

акчаларны Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә банк депозитларына урнаштыру һәм кире кайтару;

гамәлгә куючысы Татарстан Республикасы булган һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә шәхси счетлары Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган оешмаларның акчаларын җәлеп итү һәм кире кайтару.»;

г) 4 пунктта:

түбәндәге эчтәлекле яңа уналтынчы абзац өстәргә:

«җирле бюджет акчаларын исәпкә алу буенча бердәй счетта калган акчалар белән идарә итү буенча операцияләр башкарганда, җирле бюджет акчаларын исәпкә алу буенча бердәй счеттан күчерелгән акчалар һәм җирле бюджет акчаларын исәпкә алу буенча бердәй счетка күчерелгән акчалар арасындагы аерма.»;

уналтынчы абзацны 5 пункт дип санарга һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Җирле бюджетның агымдагы финанс елы башына калган акчалары муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы хокукый акты белән билгеләнгән күләмдә агымдагы финанс елында вакытлыча касса өзеклекләрен каплау өчен һәм товарлар ташуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә му-

ниципаль берәмлек исеменнән төзелгән муниципаль контрактлар шартлары нигезендә, җирле бюджет турында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карарында билгеләнгән очракларда, күрсәтелгән максатларга бюджет ассигнованиеләренең файдаланылмый калган суммасыннан артмый торган күләмдә хисап финанс елында түләнергә тиешле бу муниципаль контрактларны түләүгә бюджет ассигнованиеләрен арттыру өчен җибәрелергә мөмкин.»;

9) 29 статьяның 3 пунктында:

а) беренче абзацта «муниципаль берәмлек исеменнән» сүзләреннән соң «Россия Федерациясе валютасында эчке базарга урнаштырыла торган» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле яңа икенче абзац өстәргә:

«Муниципаль берәмлекләрнең Россия Федерациясе валютасында Россия Федерациясеннән читтә хисаплашулары рөхсәт ителми.»;

в) икенче абзацны өченче абзац дип санарга;

10) 29[1] статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы бюджетына чит ил банкларыннан чит ил валютасында кредитлар җәлеп итү Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезләмәләренә таянып башкарыла.

Татарстан Республикасына чит ил валютасында кредит алу максатларында чит ил банкларын сайлау Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасының тышкы облигация заемнары Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм кыйммәтле кәгазьләр турында Россия Федерациясе законнары, шул исәптән «Дәүләт һәм муниципаль кыйммәтле кәгазьләр эмиссиясенең һәм әйләнешенең үзенчәлекләре турында» 1998 елның 29 июлендәге 136-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләренә таянып гамәлгә ашырыла.

Номиналь бәясе чит ил валютасында күрсәтелгән Татарстан Республикасы дәүләт кыйммәтле кәгазьләрен халыкара капитал базарларына урнаштыру Россия Федерациясе дәүләт кыйммәтле кәгазьләрен халыкара капитал базарларына кертү өстенлеген исәпкә алып башкарыла.

Номиналь бәясе чит ил валютасында күрсәтелгән Татарстан Республикасы дәүләт кыйммәтле кәгазьләрен халык-

ара капитал базарларына урнаштыру операцияләрен уздыру сроклары Россия Федерациясе Финанс министрлыгы белән килештерелергә тиеш.»;

11) түбәндәге эчтәлекле яңа $29^2$ статья өстәргә:

«$29^2$ статья. **Россия Федерациясеннән читтә Россия Федерациясе валютасында Татарстан Республикасы хисаплашулары**

1. Татарстан Республикасы дәүләт кыйммәтле кәгазьләрен Россия Федерациясе валютасында Россия Федерациясеннән читтә урнаштыру юлы белән Татарстан Республикасы хисаплашулары Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм кыйммәтле кәгазьләр турында Россия Федерациясе законнары, шул исәптән «Дәүләт һәм муниципаль кыйммәтле кәгазьләр эмиссиясенең һәм әйләнешенең үзенчәлекләре турында» 1998 елның 29 июлендәге 136-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләренә таянып гамәлгә ашырыла.

Номиналь бәясе Россия Федерациясе валютасында күрсәтелгән Татарстан Республикасы дәүләт кыйммәтле кәгазьләрен халыкара капитал базарларына урнаштыру Россия Федерациясе дәүләт кыйммәтле кәгазьләрен халыкара капитал базарларына урнаштыруның өстенлеген исәпкә алып башкарыла.

Номиналь бәясе Россия Федерациясе валютасында күрсәтелгән Татарстан Республикасы дәүләт кыйммәтле кәгазьләрен халыкара капитал базарларына урнаштыру операцияләрен уздыру сроклары Россия Федерациясе Финанс министрлыгы белән килештерелергә тиеш.

2. Россия Федерациясеннән читтә Россия Федерациясе валютасында Татарстан Республикасы хисаплашулары Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән шартларны үтәп гамәлгә ашырыла.»;

12) $29^2$ статьяны $29^3$ статья дип санарга һәм анда «$29^1$ статьясы» сүзләрен «$29^1$ һәм $29^2$ статьялары» сүзләренә, «тиешле бюджет бурыч йөкләмәләрен» сүзләрен «Татарстан Республикасы, муниципаль берәмлек бурыч йөкләмәләрен» сүзләренә алмаштырырга;

13) $31^1$ статьяда:

а) 2 пунктның 1 пунктчасында «иң чик күләме» сүзләрен «исемлегә һәм җәлеп итү күләме» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 пунктта «программасы» сүзеннән соң «чираттагы финанс елына һәм план чорына» сүзләрен өстәргә;

14) 33 статьяда:

а) исемдә «иң чик күләмнәре» сүзләрен «күләме» сүзенә алмаштырырга;

б) 2 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

15) 34 статьяның исемендә «иң чик күләмнәрен» сүзләрен «күләмен» сүзенә алмаштырырга;

16) 38 статьяның 4 пунктындагы икенче абзацында «104 статьясындагы 2 пункты» сүзләрен «104 статьясындагы 4 пункты» сүзләренә алмаштырырга;

17) 41 статьяның икенче абзацында «20» санын «15» санына алмаштырырга;

18) 42 статьяның икенче абзацында «компенсацияләрнең региональ фондыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы бюджетыннан» сүзләренә алмаштырырга;

19) 44 статьяда:

а) 4 пунктның 3 пунктчасында «тышкы» сүзен төшереп калдырырга, «бер мәртәбә» сүзләреннән соң «яисә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән тәртиптә» сүзләрен өстәргә;

б) 5 пунктның беренче абзацына «иң чик күрсәткечләр бозылганда,» сүзләреннән соң «һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының 30 бүлегендә каралган очракларда» сүзләрен өстәргә;

20) $44^1$ статьяның 5 пунктындагы бишенче абзацында «компенсацияләрнең региональ фонды составына кертелә һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

21) $44^4$ статьяның 1 пунктындагы икенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

22) $44^6$ статьяда:

а) 1 пунктның икенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

б) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алу хокукларын гамәлгә ашыруга дәүләт гарантияләрен тәэмин итү, муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына субвенцияләрне исәпләп чыгару әлеге Кодексның $9^{2}$ нче кушымтасында китерелгән методика буенча гамәлгә ашырыла.»;

в) түбәндәге эчтәлекле $6^{1}$ пункт өстәргә:

«$6^{1}$. Муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына субвенцияләрне исәпләп чыгару әлеге Кодексның $9^{2.1}$ нче кушымтасында китерелгән методика буенча гамәлгә ашырыла.»;

23) $44^{10}$ статьяның 3 пунктындагы дүртенче абзацына «субсидия күләме» сүзләреннән соң «, әгәр Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында башкасы билгеләнмәгән булса,» сүзләрен өстәргә;

24) 46 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«46 статья. **Татарстан Республикасы Дәүләт Советының, муниципаль берәмлекләр вәкиллекле органнарының бюджет вәкаләтләре**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары Татарстан Республикасы бюджет системасының тиешле бюджетларын һәм аларның үтәлеше турындагы хисапларны карыйлар һәм раслыйлар, үз утырышларында, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары комитетлары, комиссияләре, эшче төркемнәре утырышлары барышында, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары үткәрә торган тыңлаулар вакытында һәм депутатлар мөрәҗәгатьләренә бәйле рәвештә тиешле бюджетлар үтәлешенең аерым мәсьәләләрен карауны тикшереп торалар, тышкы дәүләт (муниципаль) фи-

нанс контроле органнарын булдыралар һәм аларның хокукый статусларын билгелиләр, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» 2011 елның 7 февралендәге 6-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, шулай ук Татарстан Республикасы Конституциясе, әлеге Кодекс, муниципаль берәмлекләр уставлары нигезендә бүтән вәкаләтләрне башкаралар.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының бюджет мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе Конституциясендә, Россия Федерациясе Бюджет кодексында, әлеге Кодекста, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы башка норматив хокукый актларында билгеләнгән компетенциясе кысаларындагы вәкаләтләрен тәэмин итү өчен аңа Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, дәүләтнеке булган бюджеттан тыш фондлар белән идарә итү органнары тарафыннан барлык кирәкле мәгълүмат тапшырылырга тиеш.»;

25) 47[1] статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«47[1] статья. **Дәүләт (муниципаль) финанс контроле органнарының бюджет вәкаләтләре**

1. Дәүләт (муниципаль) финанс контроле органнарына керә торган Татарстан Республикасы Хисап палатасы, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, җирле администрацияләр органнары (вазыйфаи затлары) булып торучы муниципаль финанс контроле органнары тарафыннан дәүләт (муниципаль) финанс контролен гамәлгә ашыру буенча бюджет вәкаләтләре Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм әлеге Кодекста билгеләнгән.

2. Татарстан Республикасы Хисап палатасы, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары шулай ук түбәндәге бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыралар:

бюджет акчаларын тотуның сакчыл һәм нәтиҗәле булуын ачыклауга юнәлдерелгән нәтиҗәлелек аудиты;

бюджетлар турында законнар (карарлар), бюджет законнарының башка норматив хокукый актлары проектларына, шул исәптән бюджетлар күрсәткечләренең (параметрларының һәм характеристикаларының) нигезлелегенә экспертиза;

дәүләт (муниципаль) программаларга экспертиза;

бюджет процессын анализлау һәм мониторинглау, шул исәптән бюджет процессында ачыкланган тайпылышларны бетерү һәм Россия Федерациясе бюджет законнарын камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү;

бюджет акчаларының баш администраторлары тарафыннан эчке финанс контроле һәм эчке финанс аудиты үткәрүне камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү;

«Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» 2011 елның 7 февралендәге 6-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында» 2004 елның 7 июнендәге 37-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән башка мәсьәләләр.

3. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, җирле администрацияләр органнары (вазыйфаи затлары) булып торучы муниципаль финанс контроле органнары Федераль финанс-бюджет күзәтчелеге хезмәте тарафыннан Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының, җирле администрацияләр органнары (вазыйфаи затлары) булып торучы муниципаль финанс контроле органнарының бюджет вәкаләтләрен үтәвен анализлау максатларында соратып алына торган мәгълүматны һәм документларны тапшырырга тиеш.

4. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, җирле администрацияләр органнары (вазыйфаи затлары) булган муниципаль финанс контроле органнары бюджет акчаларының баш администраторлары тарафыннан эчке финанс контроле һәм эчке финанс аудиты үткәрүгә анализ ясыйлар.

5. Татарстан Республикасы Хисап палатасының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарының әлеге статьяның 1 һәм 2 пунктларында каралган бюджет вәкаләтләре

«Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» 2011 елның 7 февралендәге 6-ФЗ номерлы Федераль законда, «Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында» 2004 елның 7 июнендәге 37-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән нигезләмәләрне үтәп гамәлгә ашырыла.»;

26) 49 статьяның утыз дүртенче абзацында «һәм (яисә) төрләре» сүзләрен төшереп калдырырга;

27) 50 статьяда:

а) 2 һәм 4 пунктларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 6 пункт өстәргә:

«6. Бюджет законнарын бозулар ачыкланган очракта Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы түбәндәге карарларны кабул итәргә хокуклы:

Татарстан Республикасы бюджет системасының башка бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелгән акчалар суммасын һәм (яисә) бу акчалардан файдаланган өчен түләү суммасын һәм аларны үз вакытында кире кайтармаган өчен пеняларны һичшиксез түләттерү турында;

Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар (субвенцияләрдән тыш) бирүне туктатып тору турында.»;

28) 50[1] статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле яңа өченче абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы бюджет системасының башка бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелгән акчалар суммасын һәм (яисә) бу акчалардан файдаланган өчен түләү суммасын һәм аларны үз вакытында кире кайтармаган өчен пеняларны Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм әлеге Кодекста билгеләнгән очракларда һичшиксез түләттерүне гамәлгә ашыра;»;

б) өченче абзацны дүртенче абзац дип санарга;

в) түбәндәге эчтәлекле яңа бишенче абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы бюджетының бердәй счетында калган акчалар белән идарә итү буенча операцияләрне гамәлгә ашыра;»;

г) дүртенче – унынчы абзацларны тиешенчә алтынчы – уникенче абзацлар дип санарга;

д) унберенче һәм уникенче абзацларны тиешенчә унөченче һәм ундүртенче абзацлар дип санарга һәм аларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын баш бүлүчеләрдән, Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары баш администраторларыннан, Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре баш администраторларыннан Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында бюджет хисаплылыгы төзү өчен кирәкле материаллар ала;

Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын баш бүлүчеләрдән, Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре баш администраторларыннан, Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары баш администраторларыннан алынган бюджет хисаплылыгы нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында бюджет хисаплылыгы төзи;»;

е) унөченче һәм ундүртенче абзацларны тиешенчә унбишенче һәм уналтынчы абзацлар дип санарга;

ж) түбәндәге эчтәлекле унҗиденче абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы бюджетын казначылык аша үтәүне гамәлгә ашыра торган орган әлеге Кодекста билгеләнгән вәкаләтләр нигезендә дәүләт эчке финанс контролен башкара.»;

29) 53 статьяның 2 пунктына түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча өстәргә:

«5) Татарстан Республикасы дәүләт программаларына.»;

30) $53^2$ статьяның 3 пунктындагы беренче абзацында «Физик һәм юридик затларга дәүләт хезмәтләре күрсәтү» сүзләрен «Бюджет һәм автоном учреждениеләр тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү (эшләр башкару)» сүзләренә алмаштырырга;

31) 55 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«55 статья. **Татарстан Республикасы дәүләт программалары**

1. Татарстан Республикасы дәүләт программалары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

Татарстан Республикасы дәүләт программаларын гамәлгә ашыру сроклары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты урнаштыра торган тәртиптә аның тарафыннан билгеләнә.

Татарстан Республикасы дәүләт программаларын эшләү турында карарлар кабул итү һәм күрсәтелгән программаларны булдыру һәм гамәлгә ашыру Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый акты белән билгеләнә.

2. Татарстан Республикасы дәүләт программаларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә бюджет ассигнованиеләре күләме бюджет чыгымнарының һәрбер программага туры килә торган максатчан статьясы буенча, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының программаны раслаган норматив хокукый акты нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән раслана.

Киләсе финанс елыннан башлап гамәлгә ашыру тәкъдим ителә торган Татарстан Республикасы дәүләт программалары, шулай ук элек расланган Татарстан Республикасы дәүләт программаларына үзгәрешләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән срокларда расланырга тиеш.

Татарстан Республикасы дәүләт программалары Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы үз көченә кергән көннән алып ике айдан да соңга калмыйча аңа туры китерелергә тиеш.

3. Татарстан Республикасының һәр дәүләт программасы буенча ел саен аны гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеген бәяләү үткәрелә. Әлеге бәяләүне үткәрү тәртибе һәм аның критерийлары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

Күрсәтелгән бәяләү нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан Татарстан Республикасының элек кабул ителгән дәүләт программасын киләсе финанс елыннан башлап туктату яисә үзгәртү, шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә бюджет ассигнованиеләре күләмен үзгәртү зарурлыгы турында карар кабул ителергә мөмкин.

4. Татарстан Республикасы дәүләт программаларында җирле бюджетларга Татарстан Республикасы дәүләт программаларына туры килә торган максатларга ирешүгә юнәлдерелгән муниципаль программаларны гамәлгә ашыруга субсидияләр бирү каралырга мөмкин. Күрсәтелгән бюджетара субсидияләрне бирү шартлары һәм исәпләү методикасы Татарстан Республикасының тиешле дәүләт программасы белән билгеләнә.»;

32) 60[1] статьяда:

а) 1 пунктта «бюджеты кытлыгы» сүзләреннән соң «, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм әлеге Кодекста билгеләнгән башка күрсәткечләр» сүзләрен өстәргә;

б) 2 пунктта «Россия Федерациясе бюджет законнарында» сүзләрен «Россия Федерациясе Бюджет кодексында, федераль бюджет турында федераль законда, Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм әлеге Кодекс нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы законнарында» сүзләренә алмаштырырга;

в) 3 пунктта:

беренче абзацта «билгеләнә» сүзен «раслана» сүзенә алмаштырырга;

2[1] пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2[1]) чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет ассигнованиеләрен бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлү;»;

3 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет ассигнованиеләрен Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын баш бүлүчеләре, бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлү;»;

6 пунктчада «Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары» сүзләреннән соң «(Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан максатчан билгеләнештәге бюджетара трансфертлар исәбеннән каралган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын исәпкә алмыйча)» сүзләрен өстәргә;

7 пунктчада «әлеге Кодексның 25 статьясында билгеләнгән» сүзләрен төшереп калдырырга;

8 пунктчада «һәм Татарстан Республикасының тышкы дәүләт бурычының иң югары чиге» сүзләрен «иң югары чиге һәм (яисә) Татарстан Республикасының тышкы дәүләт бурычының иң югары чиге» сүзләренә алмаштырырга;

г) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Шартлы раслана торган (расланган) чыгымнар дигәндә бюджетлар чыгымнары классификациясе нигезендә план чорында бүленмәгән бюджет ассигнованиеләре аңлашыла.»;

33) 61 статьяның 4 пунктында:

а) тугызынчы – унберенче абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

б) уникенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлеге;»;

34) 73 статьяның 2 пунктында «елына бюджет» сүзләрен «елына Татарстан Республикасы бюджеты» сүзләренә алмаштырырга;

35) 76 статьяда:
а) өченче абзацта «кире кайтару» сүзләрен «артык бүленгән суммаларны күчерү, кире кайтару» сүзләренә алмаштырырга;
б) алтынчы абзацта «акчаларны» сүзен «артык бүленгән суммаларны, акчаларны» сүзләренә алмаштырырга, «(исәпкә алуны)» сүзләрен «(исәпкә алуны, ачыклауны)» сүзләренә алмаштырырга;

36) 77 статьяда:
а) 3 пунктта:
алтынчы абзацта «тиешле бүлекләр, бүлекчәләр, максатчан статьялар, чыгымнар төрләре» сүзләрен «бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, чыгымнар төрләре төркемнәре (төркемнәре һәм төркемчәләре)» сүзләренә алмаштырырга;
түбәндәге эчтәлекле яңа сигезенче абзац өстәргә:
«гавами норматив йөкләмәләрне финанс белән тәэмин итүгә бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, чыгымнар төрләре төркемнәре (төркемнәре һәм төркемчәләре) арасында бюджет чараларын баш бүлүчегә агымдагы финанс елында гавами йөкләмәләрне башкару өчен каралган бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләме чикләрендә яңадан бүлгән очракта;»;
сигезенче абзацны тугызынчы абзац дип санарга һәм аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«физик һәм юридик затлардан, Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында расланган күләмнәрдән тыш, максатчан билгеләнештәге субсидияләр, субвенцияләр, башка бюджетара трансфертлар һәм кире кайтарылмый торган керемнәр алган очракта, шулай ук күрсәтелгән чаралар кыскарган (кире кайтарылган яисә ихтыяҗ булмаган) очракта;»;
тугызынчы абзацны унынчы абзац дип санарга;

унынчы абзацны унберенче абзац дип санарга һәм үз көчен югалткан дип танырга;

унберенче һәм уникенче абзацларны тиешенчә уникенче һәм унөченче абзаclar дип санарга;

түбәндәге эчтәлекле ундүртенче һәм унбишенче абзацлар өстәргә:

«дәүләт бурычына хезмәт күрсәтүгә бюджет ассигнованиеләрен дәүләт бурычына хезмәт күрсәтү өчен каралган бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләме чикләрендә бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекчәләре арасында яңадан бүлгән очракта;

товарлар ташуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә төзелгән дәүләт контрактлары шартлары нигезендә, Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм әлеге Кодекста билгеләнгән таләпләргә таянып, әлеге дәүләт контрактларын үтәүгә бюджет ассигнованиеләренең агымдагы финанс елы башына файдаланылмый калган суммасыннан артмый торган күләмдә хисап финанс елында түләнергә тиешле бу дәүләт контрактларын түләү өчен бюджет ассигнованиеләрен агымдагы финанс елында арттырган очракта;»;

унөченче абзацны уналтынчы абзац дип санарга;

б) 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет язмасын төзү һәм алып бару тәртибендә җыелма бюджет язмасы күрсәткечләрен бюджет чараларын баш бүлүчеләр, бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, чыгымнар төрләре төркемнәре (төркемнәре һәм төркемчәләре) буенча раслау каралырга тиеш.

Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет язмасын төзү һәм алып бару тәртибендә җыелма бюджет язмасы күрсәткечләрен бюджетлар чыгымнары классификациясенең чыгымнар төрләре элементлары (төркемчәләре һәм элементлары) кодлары, дәүләт идарәсе секторы операцияләре классификациясенең чыгымнар кодлары буенча, шул исәптән бюджетның төрле максатчан статьялары һәм (яисә) чыгымнар төрләре өчен, дәүләт идарәсе секторы операцияләре классификациясе төркемнәре һәм статьялары, бюджет акчаларын баш бүлүчеләр өчен дифференциацияле раслау каралырга мөмкин.»;

в) 5 пунктның икенче абзацында «билгеләнергә тиеш» сүзләрен «билгеләнергә мөмкин» сүзләренә алмаштырырга;

г) 6 пунктка «бюджет ассигнованиеләре кертелә» сүзләреннән соң «, моңа Татарстан Республикасы бюджетының бердәй счетында калган акчалар белән идарә итү буенча операцияләр керми» сүзләрен өстәргә;

37) 77[1] статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасының касса планында Татарстан Республикасы бюджетының бердәй счетында калган акчалар белән идарә итү буенча операцияләрне гамәлгә ашыруга тотыла торган акча чараларының иң чик күләме билгеләнә.»;

38) 78[1] статьяның 3 пунктында «чыгымнар буенча» сүзләрен төшереп калдырырга, «баш бүлүченең (бүленүченең)» сүзләреннән соң «чыгымнар төрләре элементлары (төркемчәләре һәм элементлары) кодлары, шулай ук» сүзләренә алмаштырырга;

39) 78[2] статьяның беренче абзацында «бюджеты үтәлеше» сүзләреннән соң «, моңа Татарстан Республикасы бюджетының бердәй счетында калган акчалар белән идарә итү буенча операцияләр керми,» сүзләрен өстәргә;

40) 80[2] статьяның 2 пунктындагы өченче абзацында «классификациясенең» сүзеннән соң «чыгымнар төрләре элементлары (төркемчәләре һәм элементлары) кодлары буенча, шулай ук» сүзләрен өстәргә;

41) 93 статьяның 2 пунктында «субвенцияләр, башка бюджетара трансфертлар» сүзләреннән соң «һәм физик һәм юридик затлардан кергән түләттерелми торган керемнәр» сүзләрен өстәргә, «аларның агымдагы финанс елы башына кулланылмый калган калдыклары» сүзләрен «бюджетка Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм әлеге Кодексның 97 статьясындагы 4 пунктында билгеләнгән тәртиптә керүчеләре» сүзләренә алмаштырырга;

42) 97 статьяда:

а) 4 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Максатчан билгеләнештәге субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар рәвешендә алынган,

агымдагы финанс елында кулланылмый калган бюджетара трансфертлар үзләре бирелгән бюджет кеременә кире кайтарылырга тиеш.»;

түбәндәге эчтәлекле яңа өченче абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы бюджеты акчалары баш администраторының агымдагы финанс елында кулланылмый калган максатчан билгеләнештәге субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар рәвешендә алынган бюджетара трансфертларга ихтыяҗ булу турындагы карары нигезендә, күрсәтелгән бюджетара трансфертларның калган акчаларыннан артык булмаган күләмдәге акчалар бюджетның күрсәтелгән бюджетара трансфертларны бирү максатларына туры килә торган чыгымнарын финанс белән тәэмин итү өчен киләсе финанс елында үзләре элек бирелгән бюджет кеременә кире кайтарылырга мөмкин.»;

өченче абзацны дүртенче абзац дип санарга;

б) түбәндәге эчтәлекле 6 пункт өстәргә:

«6. Вәкаләтле оешмада яисә Татарстан Республикасының тышкы бурыч йөкләмәләрен үтәү буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының генераль агенты (агенты) функцияләрен башкара торган башка махсус оешмада Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына ачылган счетларда Татарстан Республикасы бюджетының агымдагы финанс елының 1 гыйнварына чит ил валютасында барлыкка килгән калган акчалары Татарстан Республикасы бюджетының бердәй счетына күчерелми һәм агымдагы финанс елы гыйнварының беренче декадасында касса түләүләрен башкару өчен кулланыла.»;

в) түбәндәге эчтәлекле 7 пункт өстәргә:

«7. Татарстан Республикасы бюджетының Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын алучылар тарафыннан кулланылмый калган, халыкара финанс оешмалары белән килешүләр шартлары нигезендә ачылган махсус счетлардагы калган акчалары, Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын алучылар тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетының бердәй счетына күчерелми һәм агымдагы финанс елында алар тарафыннан шул ук максатларда кулланылырга тиеш.»;

43) $97^1$ статьяның 9 пунктындагы беренче абзацында «ул төзегән муниципаль финанс контроле органына» сүзләрен «ул төзегән тышкы муниципаль финанс контроле органына» сүзләренә алмаштырырга;

44) 97$^3$ статьяда:

а) 2 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җирле бюджет үтәлеше турында еллык хисапны тышкы тикшерү, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, әлеге Кодекс таләпләрен үтәп һәм федераль законнарда билгеләнгән үзенчәлекләрне истә тотып, муниципаль берәмлек вәкиллекле органының муниципаль хокукый актында билгеләнгән тәртиптә муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

өченче абзацта «муниципаль районның вәкиллекле органы төзегән» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 4 пунктның икенче абзацында «(муниципаль финанс контроле органы)» сүзләрен «(тышкы муниципаль финанс контроле органы)» сүзләренә алмаштырырга;

в) 5 пунктта «(муниципаль финанс контроле органы)» сүзләрен «(тышкы муниципаль финанс контроле органы)» сүзләренә алмаштырырга;

45) X бүлекнең исемендә «дәүләт һәм муниципаль» сүзләрен «дәүләт (муниципаль)» сүзләренә алмаштырырга;

46) 98 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«98 статья. **Дәүләт (муниципаль) финанс контроле төрләре**

1. Дәүләт (муниципаль) финанс контроле Россия Федерациясе бюджет законнарын һәм бюджет мөнәсәбәтләрен җайга сала торган башка норматив хокукый актларны тәэмин итү максатларында гамәлгә ашырыла.

Дәүләт (муниципаль) финанс контроле тышкы һәм эчке контрольгә, алдан һәм чираттагы контроль ясауга бүленә.

2. Бюджет мөнәсәбәтләре өлкәсендә тышкы дәүләт (муниципаль) финанс контроле тиешенчә Татарстан Республикасы Хисап палатасының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарының контрольлек итү эшчәнлеге булып тора.

3. Бюджетка караган хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендә эчке дәүләт (муниципаль) финанс контроле Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының, җирле администрация органнары (вазыйфаи затлары) булып торучы муниципаль финанс контроле органнарының, Татарстан Республикасы бюджетының казначылык аша үтәлешен гамәлгә ашыра торган органның, муни-

ципаль берәмлекләрнең финанс органнарының контрольлек итү эшчәнлеге булып тора.

4. Алдан контроль ясау Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү процессында бюджет бозуларны кисәтү һәм булдырмау максатларында башкарыла.

5. Чираттагы контроль ясау Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетлары үтәлешенең законлылыгын, исәпнең һәм хисаплылыкның дөреслеген билгеләү максатларында, аларны үтәү нәтиҗәләре буенча башкарыла.»;

47) түбәндәге эчтәлекле 98[1] статья өстәргә:

«98[1] статья. **Дәүләт (муниципаль) финанс контроле үткәрү объектлары һәм ысуллары**

Дәүләт (муниципаль) финанс контроле үткәрү объектлары һәм ысуллары Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә билгеләнә.»;

48) 99 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

49) түбәндәге эчтәлекле 99[1] статья өстәргә:

«99[1] статья. **Татарстан Республикасы Хисап палатасының тышкы дәүләт финанс контролен үткәрү вәкаләтләре**

1. Татарстан Республикасы Хисап палатасының тышкы дәүләт финанс контролен үткәрү вәкаләтләре Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлекләренең гомуми принциплары турында» 2011 елның 7 февралендәге 6-ФЗ номерлы Федераль закон, әлеге Кодекс, «Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында» 2004 елның 7 июнендәге 37-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә билгеләнә.

2. Татарстан Республикасы Хисап палатасының тышкы дәүләт финанс контролен гамәлгә ашыру вәкаләтләрен башкару тәртибе әлеге Кодекс, «Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында» 2004 елның 7 июнендәге 37-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә билгеләнә.»;

50) 100 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«100 статья. **Татарстан Республикасы бюджетын казначылык аша үтәүне гамәлгә ашыручы органның эчке дәүләт финанс контролен гамәлгә ашыру вәкаләтләре**

1. Татарстан Республикасы бюджетын казначылык аша үтәүне гамәлгә ашыручы органның эчке дәүләт финанс контролен гамәлгә ашыру вәкаләтләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

операция суммасының бюджет йөкләмәләре лимитларыннан һәм (яисә) бюджет ассигнованиеләреннән артмавына контроль;

үткәрелә торган операция асылының Татарстан Республикасы бюджетын казначылык аша үтәүне гамәлгә ашыра торган органга бюджет акчаларын алучы тарафыннан тапшырылган түләү документында күрсәтелгән Россия Федерациясе бюджет классификациясе кодына туры килүенә контроль;

Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән түләнергә тиешле акча йөкләмәләре барлыкка килүне раслый торган документларның булуына контроль.

2. Эчке дәүләт финанс контроле вәкаләтләрен Татарстан Республикасы бюджетын казначылык аша үтәүне гамәлгә ашыручы орган тарафыннан гамәлгә ашырганда операцияләрне санкцияләү үткәрелә.»;

51) 101 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«101 статья. **Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының эчке дәүләт финанс контролен үткәрү вәкаләтләре**

1. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының эчке дәүләт финанс контролен үткәрү вәкаләтләре Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә билгеләнә.

2. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының эчке дәүләт финанс контролен үткәрү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актлары белән билгеләнә.

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының эчке дәүләт финанс контролен үткәрү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибендә тикшерүләр, ревизияләр һәм тикшеренүләр үткәрүнең нигезләре һәм тәртибе, шул исәптән аларны үткәрү, үткәрүнең даимилеге турында карарлар кабул итәргә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге булырга тиеш.»;

52) 101[1] һәм 102 статьяларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

53) 113 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

54) 9[2] нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы
Бюджет кодексына
9[2] нче кушымта

**Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итү, муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына субвенцияләр исәпләү методикасы**

1. Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар һәм шәһәр округлары (алга таба – муниципаль берәмлекләр) бюджетларына субвенция муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү, муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне финанс белән тәэмин итү өчен билгеләнә.

2. Әлеге Методика муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итү, муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне тәэмин итү өчен елына бер укучыга исәпләнгән финанс чыгымнары нормативын куллануга нигезләнә.

3. Субвенцияне исәпләгәндә муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында белем алучыларның планлаштырылган елга кадәрге елның 1 сентябренә уку-укыту программаларының

төрләре, юнәлешләре (профильләре), гомуми белем бирү баскычлары, белем бирү рәвешләре буенча факттагы саны кулланыла.

4. Субвенцияне исәпләү түбәндәге формула буенча гамәлгә ашырыла:

$$S_i = S_N + S_{SN} ,$$

монда:

$S_i$ – i-муниципаль берәмлегенә муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итү, муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне тәэмин итү өчен субвенция күләме;

$S_N$ – i-муниципаль берәмлегенә муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итү, муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне тәэмин итү өчен сыйныфларның норматив тулылыгы чикләрендә сыйныфлар буенча белем алучыларның санына карата исәпләнгән субвенция күләме;

$S_{SN}$ – i-муниципаль берәмлегенә муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итү өчен сыйныфларның норматив тулылыгыннан арткан сыйныфлар буенча белем алучыларның санына карата исәпләнгән субвенция күләме.

5. I-муниципаль берәмлегенә муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итү, муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне тәэмин итү өчен сыйныфларның норматив тулылыгы чикләрендә сыйныфлар буенча белем алучыларның санына карата субвенция күләмен исәпләп чыгару түбәндәге формула буенча гамәлгә ашырыла:

$$S_N = \underset{n=1}{\overset{3}{SUM}} \left(R_{ijcp} \times H_{ijcp}^{fn}\right)_n + \underset{n=1}{\overset{3}{SUM}}\left(R_{ij}^{g.p.d.} \times H_{ij}^{g.p.d.}\right)_n + \underset{n=1}{\overset{3}{SUM}}\left(R_{ij}^{d.o.} \times H_{ij}^{f.d.o.}\right)_n +$$
$$+ \underset{n=1}{\overset{3}{SUM}}\left(R_{ij}^{e.} \times H_{ij}^{e.}\right)_n + \underset{n=1}{\overset{3}{SUM}}\left(R_{ij}^{i.} \times H_{ij}^{i.}\right)_n + SUM\left(R_{ijv} \times H_{ijv}\right) ,$$

монда:

$R_{ijcp}$, $R_{ij}^{i.}$, $R_{ij}^{g.p.d.}$, $R_{ij}^{e.}$, $R_{ij}^{d.o.}$ – тиешле төп гомуми белем бирү программаларын (башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем программаларын), индивидуаль уку рәвешендәге белем алуны, озайтылган көн төркемендә белем алуны, экстернат рәвешендә белем алуны исәпкә алып гамәлгә ашыру, өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыру өчен i-муниципаль берәмлеге территориясендәге j-муниципаль гомуми белем бирү оешмасында бер белем алучыга исәпләнгән финанс чыгымнары нормативлары;

$R_{ijv}$ – i-муниципаль берәмлеге территориясендәге v-төрендәге j-муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында мәктәпкәчә белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыру өчен финанс чыгымнары нормативлары;

$H_{ijcp}^{fn}$, $H_{ij}^{i.}$, $H_{ij}^{g.p.d.}$, $H_{ij}^{e.}$, $H_{ij}^{f.d.o.}$ – i-муниципаль берәмлеге тер-риториясендәге j-муниципаль гомуми белем бирү оешмасында тиешле төп гомуми белем бирү программалары (башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем программалары) буенча, индивидуаль уку рәвешендә белем алучылар санын, озайтылган көн төркемендә белем алуны, экстернат рәвешендә белем алуны исәпкә алып, өстәмә белем бирү программалары буенча сыйныфларның норматив тулылыгы чикләрендә сыйныфларда белем алучыларның факттагы саны;

$H_{ijv}$– i-муниципаль берәмлеге территориясендәге v-төрендәге j-муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында мәктәпкәчә белемнең уку-укыту программалары буенча сыйныфларда белем алучыларның факттагы саны;

n – гомуми белем баскычы;

c – сыйныф төре;

p – укыту профиле.

6. I-муниципаль берәмлегенә муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итү өчен сыйныфларның норматив тулылыгыннан арткан сыйныфлар буенча белем алучыларның санына карата субвенция күләмен исәпләп чыгару түбәндәге формула буенча гамәлгә ашырыла:

$$S_{SN} = \underset{n=1}{\overset{3}{SUM}} \left(k \times \left(R_{ijcp} \times \left(H_{ijcp}^{f} - H_{ijcp}^{nm}\right)\right)\right)_n,$$

монда:

$R_{ijcp}$ – төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыру өчен i-муниципаль берәмлеге территориясендәге j-муниципаль гомуми белем бирү оешмасында бер белем алучыга исәпләнгән финанс чыгымнары нормативлары;

$H^{f}_{ijcp}$ – i-муниципаль берәмлеге территориясендәге j-муниципаль гомуми белем бирү оешмасында төп гомуми белем бирү программалары буенча сыйныфларда белем алучыларның факттагы саны;

$H^{nm}_{ijcp}$ – i-муниципаль берәмлеге территориясендәге j-муниципаль гомуми белем бирү оешмасында төп гомуми белем бирү программалары буенча сыйныфларның норматив тулылыгы нигезендә сыйныфларда белем алучыларның саны;

k – финанс белән тәэмин ителеш коэффициенты;

n – гомуми белем баскычы;

c – сыйныф төре;

p – укыту профиле.

7. Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итү, муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне тәэмин итү өчен финанс чыгымнары нормативлары Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.

8. Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итү, муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне тәэмин итү өчен финанс чыгымнары нормативларын исәпләү буенча методик рекомендацияләр, финанс белән тәэмин ителеш коэффициенты Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

9. Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итү, муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субвенцияләрне муниципаль берәмлекләргә бүлү чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.»;

55) түбәндәге эчтәлекле $9^{2.1}$ нче кушымта өстәргә:

Татарстан Республикасы
Бюджет кодексына
$9^{2.1}$ нче кушымта

**Муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына субвенцияләр исәпләү методикасы**

1. Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына субвенция муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү өчен билгеләнә.

2. Әлеге Методика мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында мәктәпкәчә белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыру, муниципаль мәгариф оешмаларында җайлаштырылган уку-укыту программаларын гамәлгә ашыру өчен елына бер тәрбияләнүчегә исәпләнгән финанс чыгымнары нормативын куллануга нигезләнә.

3. Субвенцияне исәпләгәндә тәрбияләнүчеләрнең, планлаштырыла торган елга кадәрге елның 1 сентябренә муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында тәрбияләнүчеләрнең категорияләре, яшь составы, муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмаларының төрләре, эш режимнары буенча төркемнәрнең иң чик тулылыгыннан артмаган факттагы саны кулланыла.

4. Субвенцияләрне исәпләү түбәндәге формула буенча гамәлгә ашырыла:

$$S_i = K_i + L_i,$$

монда:

$S_i$ − i-муниципаль берәмлегенә муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында мәктәпкәчә белемнең уку-укыту программаларын һәм җайлаштырылган уку-укыту программаларын гамәлгә ашыру өчен субвенция күләме;

$K_i$ − i-муниципаль берәмлегенә муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында (балалар бакчалары, гомуми үсеш

төрендәге балалар бакчалары, компенсацияләү төрендәге балалар бакчалары, карап тору һәм сәламәтләндерү балалар бакчалары, катнаш төрдәге балалар бакчалары, бала үсеше үзәкләре, аз комплектлы балалар бакчалары) мәктәпкәчә белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыруга субвенция күләме;

$L_i$ – i-муниципаль берәмлегенә муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында (катнаш төрдәге балалар бакчаларының коррекцияле төркемнәре, компенсацияләү төрендәге балалар бакчаларының коррекцияле төркемнәре) җайлаштырылган уку-укыту программаларын гамәлгә ашыру өчен субвенция күләме.

5. I-муниципаль берәмлегенә муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында (балалар бакчалары, гомуми үсеш төрендәге балалар бакчалары, компенсацияләү төрендәге балалар бакчалары, карап тоту һәм сәламәтләндерү балалар бакчалары, катнаш төрдәге балалар бакчалары, бала үсеше үзәкләре, аз комплектлы балалар бакчалары) мәктәпкәчә белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыруга субвенция күләмен исәпләп чыгару түбәндәге формула буенча гамәлгә ашырыла:

$$K_i = \underset{z=1}{\overset{3}{SUM}} \left(R^{ds}_{ijtxy} \times H^{ds}_{ijtxy}\right) + \underset{z=1}{\overset{3}{SUM}}\left(R^{dsov}_{ijtxy} \times H^{dsov}_{ijtxy}\right) + \underset{z=1}{\overset{3}{SUM}}\left(R^{dskomp}_{ijtxy} \times H^{dskomp}_{ijtxy}\right) +$$
$$+ \underset{z=1}{\overset{3}{SUM}}\left(R^{dspo}_{ijtxy} \times H^{dspo}_{ijtxy}\right) + \underset{z=1}{\overset{3}{SUM}}\left(R^{dskomb}_{ijtxy} \times H^{dskomb}_{ijtxy}\right) + \underset{z=1}{\overset{3}{SUM}}\left(R^{crr}_{ijtxy} \times H^{crr}_{ijtxy}\right) +$$
$$+ \underset{z=1}{\overset{3}{SUM}}\left(R^{mds}_{ijtxy} \times H^{mds}_{ijtxy}\right),$$

монда:

$R^{ds}_{ijtxy}, R^{dsov}_{ijtxy}, R^{dskomp}_{ijtxy}, R^{dspo}_{ijtxy}, R^{dskomb}_{ijtxy}, R^{crr}_{ijtxy}, R^{mds}_{ijtxy}$ – мәктәпкәчә белемнең тиешле уку-укыту программаларын гамәлгә ашыру өчен i-муниципаль берәмлеге территориясендәге j-муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмасында (балалар бакчалары, гомуми үсеш төрендәге балалар бакчалары, компенсацияләү төрендәге балалар бакчалары, карап тору һәм сәламәтләндерү балалар бакчалары, катнаш төрдәге балалар бакчалары, бала үсеше үзәкләре, аз комплектлы балалар бакчалары) бер тәрбияләнүчегә исәпләнгән финанс чыгымнары нормативы;

$H^{ds}_{ijtxy}, H^{dsov}_{ijtxy}, H^{dskomp}_{ijtxy}, H^{dspo}_{ijtxy}, H^{dskomb}_{ijtxy}, H^{crr}_{ijtxy}, H^{mds}_{ijtxy}$ – i-муниципаль берәмлеге территориясендәге j-муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмасында (балалар бакчалары, гомуми үсеш төрендәге балалар бакчалары, компенсацияләү төрендәге балалар бакчалары, карап тору һәм сәламәтләндерү балалар бакчалары, катнаш төрдәге балалар бакчалары, бала үсеше үзәкләре, аз комплектлы балалар бакчалары) мәктәпкәчә белемнең тиешле уку-укыту

программалары буенча белем алучы тәрбияләнүчеләрнең әлеге Методиканың 3 пункты нигезендә билгеләнә торган саны;

*t* – муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмасының территориаль урнашуы (шәһәр, авыл җире);

*x* – муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмасында (муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмасы төркемнәре) атнага эш көннәре саны;

*y* – муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмасында (муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмасы төркемендә) балаларның булу дәвамлылыгы;

*z* – муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмасы төркемендә тәрбияләнүчеләрнең яшь составы;

*ds* – балалар бакчалары;

*dsov* – гомуми үсеш төрендәге балалар бакчалары;

*dskomp* – компенсацияләү төрендәге балалар бакчалары;

*dspo* – карап тоту һәм сәламәтләндерү балалар бакчалары;

*dskomb* – катнаш төрдәге балалар бакчалары;

*crr* – бала үсеше үзәкләре;

*mds* – аз комплектлы балалар бакчалары.

6. I-муниципаль берәмлегенә муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында (катнаш төрдәге балалар бакчаларының коррекцияле төркемнәре, компенсацияләү төрендәге балалар бакчаларының коррекцияле төркемнәре) җайлаштырылган уку-укыту программаларын гамәлгә ашыруга субвенция күләмен исәпләп чыгару түбәндәге формула буенча гамәлгә ашырыла:

$$L_i = \underset{z=1}{\overset{3}{SUM}} \left(R_{ijztxq}^{kgkomb} \times H_{ijztxq}^{kgkomb}\right) + \underset{z=1}{\overset{3}{SUM}} \left(R_{ijztxq}^{kgkomp} \times H_{ijztxq}^{kgkomp}\right),$$

монда:

$R_{ijztxq}^{kgkomb}, R_{ijztxq}^{kgkomp}$ – муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмасында (катнаш төрдәге балалар бакчаларының коррекцияле төркемнәре, компенсацияләү төрендәге балалар бакчаларының коррекцияле төркемнәре) тиешле җайлаштырылган уку-укыту программаларын гамәлгә ашыру өчен i-муниципаль берәмлеге территориясендәге j-муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмасының бер тәрбияләнүчесенә исәпләнгән финанс чыгымнары нормативлары;

$H_{ijztxq}^{kgkomb}, H_{ijztxq}^{kgkomp}$ – i-муниципаль берәмлеге территориясендәге j-муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмасында (катнаш төрдәге балалар бакчаларының коррекцияле төркемнәре,

компенсациялəү төрендəге балалар бакчаларының коррекцияле төркемнəре) муниципаль мəктəпкəчə мəгариф оешмасында тиешле җайлаштырылган уку-укыту программалары буенча белем алучы тəрбиялəнүчелəрнең əлеге Методиканың 3 пункты нигезендə билгелəнə торган саны;

*q* − муниципаль мəктəпкəчə мəгариф оешмасында (муниципаль мəктəпкəчə мəгариф оешмасы төркемендə) тəрбиялəнүчелəр категориясе (авыру төре буенча);

*kgkomb* – катнаш төрдəге балалар бакчаларының коррекцияле төркемнəре;

*kgkomp* – компенсациялəү юнəлешендəге балалар бакчаларының коррекцияле төркемнəре.

7. Муниципаль мəктəпкəчə мəгариф оешмаларында һəркем өчен мөмкин булган һəм түлəүсез мəктəпкəчə белем алуга хокукларны гамəлгə ашыруның дəүлəт гарантиялəрен тəэмин итү өчен финанс чыгымнары нормативлары Татарстан Республикасы законы белəн билгелəнə.

8. Муниципаль мəктəпкəчə мəгариф оешмаларында һəркем өчен мөмкин булган һəм түлəүсез мəктəпкəчə белем алуга хокукларны гамəлгə ашыруның дəүлəт гарантиялəрен тəэмин итү өчен финанс чыгымнары нормативын исəплəү буенча методик рекомендациялəр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгелəнə.

9. Муниципаль мəктəпкəчə мəгариф оешмаларында һəркем өчен мөмкин булган һəм түлəүсез мəктəпкəчə белем алуга хокукларны гамəлгə ашыруның дəүлəт гарантиялəрен тəэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субвенциялəрне муниципаль берəмлеклəргə бүлү чираттагы финанс елына һəм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белəн раслана.».

**2 статья**

«Муниципаль районнарның җирле үзидарə органнарына җирлеклəрнең региональ финанс ярдəме фондыннан җирлеклəргə дотациялəр исəплəү һəм бирү буенча Татарстан Республикасы дəүлəт вəкалəтлəрен тапшыру турында» 2005 елның 22 декабрендəге 132-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дəүлəт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 12 (II өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш) түбəндəге үзгəрешлəрне кертергə:

1) 4 статьяда:

а) 1 өлештә «региональ компенсацияләр фондыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы бюджетыннан» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештә «региональ компенсацияләр фондыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы бюджетыннан» сүзләренә алмаштырырга;

2) 13 статьяның 1 өлешен үз көчен югалткан дип танырга;

3) 1 нче кушымтада:

а) исемдә «региональ компенсацияләр фондыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы бюджетыннан» сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 пунктта «региональ компенсацияләр фондыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы бюджетыннан» сүзләренә алмаштырырга;

в) 3 пунктта:

беренче абзацта «региональ компенсацияләр фондыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы бюджетыннан» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «региональ компенсацияләр фондыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы бюджетыннан» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «региональ компенсацияләр фондыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы бюджетыннан» сүзләренә алмаштырырга;

4) 2 нче кушымтада:

а) исемдә «Региональ компенсацияләр фондыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы бюджетыннан» сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 пунктта «региональ компенсацияләр фондыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы бюджетыннан» сүзләренә алмаштырырга;

в) 3 пунктта «Региональ компенсацияләр фондыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы бюджетыннан» сүзләренә алмаштырырга;

г) 11 пунктның беренче абзацында «Региональ компенсацияләр фондыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы бюджетыннан» сүзләренә алмаштырырга.

**3 статья**

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрен төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 143-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 12 (IV өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2012, № 12 (I өлеш) 11 статьясындагы 1 өлешен үз көчен югалткан дип танырга.

**4 статья**

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 12 (IV өлеш); 2010, № 7 (II өлеш) 18 статьясындагы 1 өлешен үз көчен югалткан дип танырга.

**5 статья**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 146-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 12 (IV өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 11; 2008, № 10 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяда:

а) 2 өлештә «Татарстан Республикасы бюджеты составында төзелә торган региональ компенсацияләр фондыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы бюджетыннан» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 өлештә «региональ компенсацияләр фондыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы бюджетыннан» сүзләренә алмаштырырга;

2) 11 статьяның 1 өлешен үз көчен югалткан дип танырга;

3) 1 нче кушымтада:

а) исемдә «региональ компенсацияләр фондыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы бюджетыннан» сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 пунктта «региональ компенсацияләр фондыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы бюджетыннан» сүзләренә алмаштырырга;

в) 2 пунктның беренче абзацында «региональ компенсацияләр фондыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы бюджетыннан» сүзләренә алмаштырырга.

**6 статья**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына мәгариф өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 22 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 2 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2008, № 8 (II өлеш); 2010, № 1 – 2, № 7 (II өлеш) 11 статьясындагы 1 өлешен үз көчен югалткан дип танырга.

**7 статья**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына сәламәтлек саклау өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 16 мартындагы 19-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 3 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2012, № 7 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяда:

а) 1 өлештә «Татарстан Республикасы бюджеты составында төзелүче компенсацияләрнең төбәк фондыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы бюджетыннан» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 өлештә «компенсацияләрнең төбәк фондыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы бюджетыннан» сүзләренә алмаштырырга;

в) 4 өлештә «компенсацияләрнең төбәк фондыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы бюджетыннан» сүзләренә алмаштырырга;

2) 11 статьяның 1 өлешен үз көчен югалткан дип танырга;

3) 1 нче кушымтада:

а) исемдә «компенсацияләрнең төбәк фондыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы бюджетыннан» сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 пунктта «компенсацияләрнең төбәк фондыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы бюджетыннан» сүзләренә алмаштырырга;

4) 2 нче кушымтада:

а) исемдә «компенсацияләрнең төбәк фондыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы бюджетыннан» сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 пунктта «компенсацияләрнең төбәк фондыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы бюджетыннан» сүзләренә алмаштырырга.

**8 статья**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 7 апрелендәге 29-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 4; 2010, № 7 (II өлеш) 11 статьясындагы 1 өлешен үз көчен югалткан дип танырга.

**9 статья**

«Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарына халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 28 апрелендәге 32-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 4; 2010, № 7 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяда:

а) 1 өлештә «компенсацияләрнең төбәк фондыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы бюджетыннан» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештә «компенсацияләрнең төбәк фондыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы бюджетыннан» сүзләренә алмаштырырга;

2) 11 статьяның 1 өлешен үз көчен югалткан дип танырга;

3) 1 нче кушымтада:

а) исемдә «компенсацияләрнең төбәк фондыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы бюджетыннан» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 пунктта:

беренче абзацта «компенсацияләрнең төбәк фондыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы бюджетыннан» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «компенсацияләрнең төбәк фондыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы бюджетыннан» сүзләренә алмаштырырга.

**10 статья**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына аерым категориядәге гражданнарга акчалата түләүләрне һәм өстәмә түләүне гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 7 декабрендәге 75-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяның 1 өлешендә «Татарстан Республикасы бюджеты составында төзелүче региональ компенсацияләр фондыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы бюджетыннан» сүзләренә алмаштырырга;

2) 11 статьяның 1 өлешен үз көчен югалткан дип танырга;

3) 1 нче кушымтаның исемендә «региональ компенсацияләр фондыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы бюджетыннан» сүзләренә алмаштырырга;

4) 2 нче кушымтаның исемендә «региональ компенсацияләр фондыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы бюджетыннан» сүзләренә алмаштырырга.

**11 статья**

«Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль район составына керүче җирлекләр бюджетларына субвенцияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 11 декабрендәге 78-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) преамбулада «җирлекләр бюджетларына» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы бюджетыннан» сүзләрен өстәргә;

2) 1 статьяда:

а) беренче абзацта «компенсацияләрнең региональ фондыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы бюджетыннан» сүзләренә алмаштырырга;

б) өченче абзацта «компенсацияләрнең региональ фондыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы бюджетыннан» сүзләренә алмаштырырга;

3) 4 статьяның 1 өлешендә «компенсацияләрнең төбәк фондыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы бюджетыннан» сүзләренә алмаштырырга;

4) 11 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

5) 2 нче кушымтада:

а) исемдә «компенсацияләрнең региональ фондыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы бюджетыннан» сүзләренә алмаштырырга;

б) беренче абзацта «компенсацияләрнең региональ фондыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы бюджетыннан» сүзләренә алмаштырырга.

**12 статья**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2012, № 1, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 1, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 7) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 бүлекне үз көчен югалткан дип танырга;

2) 7.1 статьяда «муниципаль берәмлек бюджетына кагылышлы» сүзләрен, «, шулай ук 6.1– 6.3 статьяларында» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 7.7 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

4) 8.1 статьяда:

а) 13 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

б) 14 өлештә «6.1– 6.3 статьяларында (җирле бюджет акчалары өлешендә)» сүзләрен төшереп калдырырга.

**13 статья**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына архив эше өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләре бирү турында» 2007 елның 24 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш) 10 статьясындагы 1 өлешен үз көчен югалткан дип танырга.

**14 статья**

«Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт тикшереп торуын һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 12 (II өлеш); 2010, № 5 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш); 2013, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 1 өлешендә «региональ компенсацияләр фондыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы бюджетыннан» сүзләренә алмаштырырга;

2) 11 статьяның 1 өлешен үз көчен югалткан дип танырга.

**15 статья**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләре бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 3; 2010, № 7 (II өлеш) 10 статьясындагы 1 өлешен үз көчен югалткан дип танырга.

**16 статья**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 19 декабрендәге 123-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2012,

№ 11 (I өлеш) 11 статьясындагы 1 өлешен үз көчен югалткан дип танырга.

**17 статья**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» 2010 елның 30 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 7 (II өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяда «, шулай ук 6.1 – 6.3 статьяларында (җирле бюджет акчалары өлешендә)» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 10 статьяның 1 өлешен үз көчен югалткан дип танырга.

**18 статья**

«Муниципаль районнарның һәм «Чаллы шәһәре» шәһәр округының җирле үзидарә органнарына хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2012 елның 13 гыйнварындагы 9-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 1) 11 статьясындагы 1 өлешен үз көчен югалткан дип танырга.

**19 статья**

1. Түбәндәгеләрне үз көчләрен югалткан дип танырга:

1) «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2006 елның 22 июнендәге 46-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 6 (I өлеш); 2007, № 8; 2008, № 8 (III өлеш) 1 статьясындагы 13 пунктын;

2) «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2007 елның 2 августындагы 38-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 8; 2009, № 1, № 7 – 8 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7) 1 статьясындагы 26 пунктының сигезенче абзацын, 36 пунктының дүртенче һәм унөченче абзацларын, 49 пунктының «б» һәм «г» пунктчаларын,

63 пунктының уналтынчы – унсигезенче абзацларын, 95, 97 һәм 98 пунктларын;

3) «Административ хокук бозган өчен салына торган акчалата түләтүне белдерү алымын үзгәртү өлешендә Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 7 ноябрендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 11; 2010, № 3) 1 статьясындагы 25 – 27 пунктларын;

4) «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2011 елның 18 ноябрендәге 88-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 11 (I өлеш) 1 статьясындагы 17 пунктының «б» пунктчасының унынчы – уникенче абзацларын;

5) «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 2013 елның 18 июнендәге 47-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш) 1 статьясындагы 23 пунктын һәм 24 пунктының егерме беренче – егерме өченче абзацларын.

2. «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 5 июлендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш) 1 статьясындагы 16 пунктының «в» пунктчасын 2014 елның 1 гыйнварыннан үз көчен югалткан дип танырга.

**20 статья**

1. Әлеге Закон, гамәлгә керүенең шушы статья белән башка сроклары билгеләнгән нигезләмәләреннән кала, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 14 пунктының «а» пунктчасы, 15, 17 пунктлары, 36 пунктының «а» пунктчасы, 22

пунктының «б» һәм «в» пунктчалары, 54, 55 пунктлары 2014 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә керә.

3. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 20 статьясындагы дүртенче абзацы, $20^1$, 55, $60^1$ статьялары, 77 статьясындагы 4 пункты, $78^1$ статьясындагы 3 пункты, $80^2$ статьясындагы 2 пунктының өченче абзацы нигезләмәләре (әлеге Закон редакциясендә) Татарстан Республикасы бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә карата 2014 елга, 2015 һәм 2016 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетыннан башлап кулланыла.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 16 октябре
№ 79-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 1148. Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 26 сентябрендә
кабул ителде

### 1 статья

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрен төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 143-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 2 өлешендә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 12 (IV өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2012, № 12 (I өлеш) «төзү һәм аларның» сүзләрен төшереп калдырырга.

### 2 статья

«Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында» 2010 елның 14 октябрендәге 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы 4 өлешендә (Татарстан Дәүләт Со-

веты Җыелма басмасы, 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 10 (I өлеш) «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы» сүзләрен төшереп калдырырга, «Балигъ булмаганнар эшләре» сүзләреннән соң «һәм аларның хокукларын яклау» сүзләрен өстәргә.

**3 статья**

«Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» 2011 елның 20 маендагы 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 5) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре (алга таба – комиссияләр) балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органнарының һәм учреждениеләренең балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген, сукбайлыгын, хокук бозуларын һәм җәмгыятькә каршы гамәлләрен кисәтү, шуңа китерә торган сәбәпләрне һәм шартларны ачыклау һәм бетерү, балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итү, социаль куркыныч хәлдәге балигъ булмаганнарны социаль-педагогик реабилитацияләү, балигъ булмаганнарны җинаятьләр кылуга һәм җәмгыятькә каршы гамәлләр башкаруга җәлеп итү очракларын ачыклау һәм булдырмый калу буенча эшчәнлеген координацияләү максатларында төзелә торган даими эшләп килүче коллегиаль органнар була.»;

2) 3 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3 статья. **Комиссияләрнең төп бурычлары**

Комиссияләрнең төп бурычлары түбәндәгеләр:

1) балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органнарының һәм учреждениеләренең эшчәнлеген координацияләү;

2) балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау һәм торгызу, аларны дискриминацияләүнең барлык рәвешләреннән, физик яисә психик җәберләүдән, мәсхәрәләүдән, тупас мөнәсәбәттән, сексуаль һәм бүтән төрле эксплуатацияләүдән яклау чараларын гамәлгә ашыруны тәэмин итү;

3) социаль куркыныч хәлдәге балигъ булмаганнарны социаль-педагогик реабилитацияләү чараларын гамәлгә ашыруны тәэмин итү;

4) балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген, сукбайлыгын, хокук бозуларын һәм җәмгыятькә каршы гамәлләрен кисәтү, шуңа китерә торган сәбәпләрне һәм шартларны ачыклау, анализлау һәм бетерү;

5) балигъ булмаганнарны җинаятьләр кылуга һәм җәмгыятькә каршы гамәлләр башкаруга җәлеп итү очракларын ачыклау һәм булдырмый калу чараларын гамәлгә ашыруны тәэмин итү;

6) балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалауга, аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауга бәйле эшчәнлекнең өстенлекле юнәлешләренә кагылышлы төп мәсьәләләрне хәл итүгә карата килешенгән алымнар эшләү;

7) балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген, сукбайлыгын, хокук бозуларын һәм җәмгыятькә каршы гамәлләрен профилактикалау, аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау мәсьәләләре буенча дәүләт теркәве узган иҗтимагый берләшмәләр, дини оешмалар, шулай ук бүтән оешмалар һәм гражданнар белән үзара хезмәттәшлек;

8) балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органнарының һәм учреждениеләренең уңай эш тәҗрибәсен гомумиләштерү һәм тарату, аларга оештыру-методик ярдәм күрсәтү;

9) федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән бүтән бурычлар.»;

3) 10 статьяның 1 өлешендәге 7 пунктында «Россия Федерациясе законнарында» сүзләрен «федераль законнарда» сүзләренә алмаштырырга;

4) 11 статьяның 20 пунктында «Россия Федерациясе законнары» сүзләрен «федераль законнар» сүзләренә алмаштырырга;

5) 12 статьяның 2 өлешендә «Россия Федерациясе законнары» сүзләрен «федераль законнар» сүзләренә алмаштырырга;

6) 13 статьяда:

а) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) балигъ булмаганнарның хокук бозуларына һәм җәмгыятькә каршы гамәлләренә китерә торган сәбәпләрне һәм шартларны бетерү турында тиешле органнарга һәм учреждениеләргә тәкъдимнәр кертәләр, шулай ук административ хокук бозуны

кылуга китергән сәбәпләрне һәм шартларны бетерү хакында тиешле оешмаларга һәм тиешле вазыйфаи затларга Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы нигезендә күрсәтмәләр кертәләр;»;

б) 7, 8 һәм 9 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) ябык типтагы махсус укыту-тәрбияләү учреждениеләрендә балигъ булмаганнарны тотуга бәйле мәсьәләләр, шулай ук федераль законнарда каралган бүтән мәсьәләләр буенча тиешле органнар яисә учреждениеләр белән берлектә судка тәкъдим итү өчен материаллар әзерлиләр;

8) җинаять-башкару системасы учреждениеләреннән азат ителгән йә махсус укыту-тәрбияләү учреждениеләреннән кайткан балигъ булмаганнарны хезмәттә һәм көнкүрештә урнаштыруда ярдәм күрсәтүне, дәүләт ярдәменә мохтаҗ башка балигъ булмаганнарны урнаштыру рәвешләрен билгеләүдә ярдәм итүне, шулай ук балигъ булмаганнарны социаль реабилитацияләү буенча федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка функцияләрне гамәлгә ашыруны тәэмин итәләр;

9) гомуми белем алмаган балигъ булмаганнарны мәгариф оешмасыннан чыгару хакында һәм «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очракларда аларга белем бирүнең башка мәсьәләләре буенча мәгариф оешмасының идарә органы тәкъдимнәрен карыйлар;»;

в) 18 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә, балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау эше турында хисаплар, шулай ук муниципаль берәмлекләрдә балигъ булмаганнарның сукбайлыгын, күзәтүчесезлеген, наркоманиясен, токсикоманиясен, алкоголизмын, хокук бозуларын, үлемнәрен һәм имгәнүләрен кисәтү чаралары турында, аларның хезмәт, торак һәм башка хокуклары бозылу хакында бүтән мәгълүмат әзерлиләр һәм аны Республика комиссиясенә, җирле үзидарә органнарына җибәрәләр һәм бу өлкәдәге вәзгыятьне яхшырту буенча тәкъдимнәр кертәләр;»;

г) 20 пунктта «учреждениеләренә» сүзен «оешмаларына» сүзенә алмаштырырга;

д) 21 пунктта «Россия Федерациясе законнарында» сүзләрен «федераль законнарда» сүзләренә алмаштырырга;

е) 22 пунктта «учреждениесенә» сүзен «оешмасына» сүзенә алмаштырырга;

ж) 24, 26, 28 пунктларда «Россия Федерациясе законнарында» сүзләрен «федераль законнарда» сүзләренә, 29 пунктта «Россия Федерациясе законнары» сүзләрен «федераль законнар» сүзләренә алмаштырырга;

7) 14 статьяда:

а) 1 өлештә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) муниципаль комиссия инициативасы белән кузгатылган эшләрне караганда, шулай ук балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауга бәйле башка эшләрне караганда, федераль законнарда билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә судка үз вәкилләрен җибәрергә;»;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) федераль дәүләт хакимияте органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарына балигъ булмаганнарның хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылышлы мәсьәләләр буенча, балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген, хокук бозуларын, җәмгыятькә каршы башка гамәлләрен профилактикалау чараларын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр кертү турында һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына тиешле тәкъдимнәр һәм күрсәтмәләр кертү хакында Республика комиссиясенә үтенечнамә юлларга.»;

б) 2 өлештә «Россия Федерациясе законнары» сүзләрен «федераль законнар» сүзләренә алмаштырырга;

8) 15 статьяның 8 пунктында «Россия Федерациясе законнарында» сүзләрен «федераль законнарда» сүзләренә алмаштырырга;

9) 17 статьяда:

а) 1 өлештә «мәгариф учреждениеләре» сүзләрен «мәгариф оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле $5^1$ өлеш өстәргә:

«$5^1$. Комиссиянең үз компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча кабул ителә торган һәм балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген, хокук бозуларын профилактикалау системасы органнары һәм учреждениеләре тарафыннан үтәү өчен җибәрелә торган карарында балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозулар (ачыкланганнары), балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлегенә, сукбайлыгына, хокук

бозуларына һәм җәмгыятькә каршы гамәлләренә китерә торган сәбәпләр һәм шартлар, аларны бетерү чаралары һәм бу чараларны кабул итү сроклары күрсәтелә.»;

в) 10 өлештә «күрсәтмәсен алганда,» сүзләреннән соң «әлеге статьяның 101 һәм 102 өлешләрендә каралган очраклардан тыш,» сүзләрен өстәргә;

г) түбәндәге эчтәлекле $10^{1}$ һәм $10^{2}$ өлешләр өстәргә:

«$10^{1}$. Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органнары һәм учреждениеләре комиссиягә әлеге статьяның $5^{1}$ өлеше нигезендә чыгарылган карарны үтәү буенча кабул ителгән чаралар турында шушы карарда күрсәтелгән срокта хәбәр итәргә тиеш.

$10^{2}$. Оешмалар һәм вазыйфаи затлар, Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына нигезләнеп, административ хокук бозуны кылуга китергән сәбәпләрне һәм шартларны бетерү хакында муниципаль комиссия тарафыннан кертелгән күрсәтмәне алган көннән алып 30 көн эчендә аны карарга һәм күрелгән чаралар турында муниципаль комиссиягә хәбәр итәргә тиеш.»;

д) 11 өлештә «Россия Федерациясе законнарында» сүзләрен «федераль законнарда» сүзләренә алмаштырырга;

10) 18 статьяның 2 өлешендәге 7 һәм 8 пунктларында «Россия Федерациясе законнарында» сүзләрен «федераль законнарда» сүзләренә алмаштырырга;

11) 21 статьяда:

а) 1 өлештә «Россия Федерациясе законнарында» сүзләрен «федераль законнарда» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Муниципаль комиссияләр эшчәнлеген тикшереп тору Республика комиссиясе тарафыннан гамәлгә ашырыла.».

**4 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 18 октябре
№ 80-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1149. Балык Бистәсе муниципаль районының Олы Елга һәм Сорочьи Горы авыл җирлекләрен үзгәртеп кору һәм «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 26 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Балык Бистәсе муниципаль районы составындагы «Олы Елга авыл җирлеге» муниципаль берәмлеген әлеге җирлектәге халыкның җирлекнең вәкиллекле органы аша белдерелгән ризалыгы белән һәм «Сорочьи Горы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеген әлеге җирлектәге халыкның гражданнар җыенында белдерелгән ризалыгы нигезендә күрсәтелгән җирлекләрне административ үзәге Олы Елга авылы булган «Олы Елга авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенә (алга таба – яңа төзелгән «Олы Елга авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге) берләштерү юлы белән үзгәртеп корырга.

**2 статья**

1. Яңа төзелгән «Олы Елга авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең беренче чакырылыш вәкиллекле органы депутатларының һәм беренче башлыгының вәкаләтләре чорын ике ел дип билгеләргә.

2. Яңа төзелгән «Олы Елга авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең беренче чакырылыш вәкиллекле органы депутатлары санын ун кеше тәшкил итә дип билгеләргә.

3. Яңа төзелгән «Олы Елга авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарына сайлауларны билгеләү, сайлауларны әзерләү һәм үткәрү законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда гамәлгә ашырыла.

**3 статья**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 34 статьясындагы 5 өлешендә каралган тәртиптә җирле референдумда кабул ителә торган яңа төзелгән «Олы Елга авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары структурасы турындагы карарда башкасы билгеләнмәгән булса, түбәндәгеләрне билгеләргә:

1) яңа төзелгән «Олы Елга авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең беренче башлыгы әлеге муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан яшерен тавыш бирү юлы белән үз составыннан сайлап куела.

Яңа төзелгән «Олы Елга авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең беренче чакырылыш вәкиллекле органы депутаты, вәкиллекле орган депутатларының билгеләнгән санынан яртысыннан артыграгы аны хуплап тавыш бирсә, бу муниципаль берәмлекнең сайлап куелган башлыгы дип санала.

Яңа төзелгән «Олы Елга авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең башлыгын сайлап куйганчы, бу муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы утырышын вәкиллекле органның яше буенча иң өлкән депутаты ача һәм алып бара;

2) яңа төзелгән «Олы Елга авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең сайлап куелган башлыгы бу муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы рәисе вәкаләтләрен башкара.

**4 статья**

«Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 37-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (III өлеш); 2008, № 11 (I өлеш); 2010, № 5 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяда:

а) алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Олы Елга авыл җирлеге: Олы Елга (административ үзәк), Сорочьи Горы, Казаклар авыллары, Кама поселогы;»;

б) егерме беренче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

2) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:



**«Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре**

| Карта-схемадагы № | Муниципаль берәмлек |
|---|---|
| 1 | Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы |
| 2 | Анатыш авыл җирлеге |
| 3 | Балыклы Чүкәй авыл җирлеге |
| 4 | Бәтке авыл җирлеге |
| 5 | Биектау авыл җирлеге |
| 6 | Олы Елга авыл җирлеге |
| 7 | Олы Кульга авыл җирлеге |
| 8 | Зур Мәшләк авыл җирлеге |
| 9 | Олы Әшнәк авыл җирлеге |
| 10 | Олы Солтан авыл җирлеге |
| 11 | Казак Чаллысы авыл җирлеге |
| 12 | Корноухово авыл җирлеге |
| 13 | Күгәрчен авыл җирлеге |
| 14 | Күки авыл җирлеге |
| 15 | Котлы Бөкәш авыл җирлеге |
| 16 | Масловка авыл җирлеге |
| 17 | Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге |
| 18 | Яңа Арыш авыл җирлеге |
| 19 | Полянка авыл җирлеге |
| 20 | Рус Әшнәге авыл җирлеге |
| 21 | Троицкий Урай авыл җирлеге |
| 22 | Уракчы авыл җирлеге |
| 23 | Шомарбаш авыл җирлеге |
| 24 | Югары Ырга авыл җирлеге |
| 25 | Шумбут авыл җирлеге |
| 26 | Шумково авыл җирлеге |
| 27 | Балтач авыл җирлеге |

»;

3) 8 нче кушымтада:

а) икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Олы Елга авыл җирлеге Олы Әшнәк, Масловка, Рус Әшнәге авыл җирлекләре, Алексеевск һәм Лаеш муниципаль районнары белән чиктәш.»;

б) дүртенче абзацта «Олы Елга, Сорочьи Горы авыл җирлекләре һәм Лаеш муниципаль районы чикләре тоташкан урында Сорочьи Горы авылыннан 2,0 км көньяк-көнбатышта урнашкан 49 нчы тоташу ноктасыннан» сүзләрен «Олы Елга авыл җирлеге, Алексеевск һәм Лаеш муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Сорочьи Горы авылыннан 200 м көньяк-көнбатышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X = 429494,20, Y = 1358656,60 координаталы 52 нче (57 нче) тоташу ноктасыннан» сүзләренә алмаштырырга;

в) җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Олы Елга авыл җирлеге чиге Масловка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 50 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м көньяк-көнчыгышка таба, 50 м көнчыгышка таба уза, «Лаеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Балык Бистәсе участок урманчылыгындагы 160 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап 30 м бара, аннары 500 м, сынык сызык ясап, әлеге урман кварталының аерымланган кишәрлеген кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба, 2,6 км көньякка таба, 500 м көньяк-көнбатышка таба һәм 750 м көньяк-көнчыгышка таба уза, алга таба «Кызыл Йолдыз урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Балык Бистәсе участок урманчылыгындагы 139 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап 30 м көньяк-көнчыгышка таба, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 139 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап 40 м, 450 м агачлык-куаклыклар массивының көнчыгыш чиге буйлап, 800 м, Олы Елга – Кама профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,0 км, урман полосасын кисеп үтеп, әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 950 м, Олы Елга – Кама профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, әлеге урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 1,4 км әлеге автомобиль юлы буйлап бара, аннары 50 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м урман утыртмаларының көнчыгыш чиге буйлап, 900 м 144 нче урман кварталының көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап уза, аннары, әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 350 м көньяк-көнбатышка таба һәм 350 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре

буйлап уза, 100 м көньяк-көнбатышка таба Олы Елга – Кама профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, алга таба 20 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары 150 м төньяк-көнчыгышка таба урман массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м 142 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м 142 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, алга таба 150 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м көньяк-көнчыгышка таба, 150 м төньяк-көнчыгышка таба, 250 м, Олы Елга – Кама профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка таба, 550 м төньяк-көнчыгышка таба, 150 м көньяк-көнчыгышка таба, 300 м төньяк-көнчыгышка таба бара, аннары 350 м төньяк-көнчыгышка таба 142 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, алга таба 100 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м көнчыгышка таба, 100 м көньяк-көнбатышка таба бара, аннары 350 м көньяк-көнбатышка таба 142 нче урман кварталы буйлап уза, алга таба 100 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба бара, алга таба, текә ярны кисеп үтеп, 100 м көньяк-көнчыгышка таба «Лаеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Балык Бистәсе участок урманчылыгындагы 142 нче урман кварталы буйлап, 2,2 км Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап сусаклагычның уң текә ярына кадәр, Олы Елга, Масловка авыл җирлекләре һәм Алексеевск муниципаль районы чикләре тоташкан урында Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X = 430610,97, Y=1363305,42 координаталы 53 нче тоташу ноктасына кадәр бара.»;

г) сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Олы Елга авыл җирлеге чиге Алексеевск муниципаль районы белән чиктәш җирдә 53 нче тоташу ноктасыннан алып Балык Бистәсе муниципаль районы чиге буйлап 52 нче (57 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.»;

4) 18 нче кушымтада:

а) икенче абзацта «, Сорочьи Горы» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) дүртенче абзацта «Масловка, Сорочьи Горы» сүзләрен «Олы Елга, Масловка» сүзләренә алмаштырырга;

в) бишенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

г) алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Масловка авыл җирлеге чиге Олы Елга авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Олы Елга, Масловка һәм Рус Әшнәге авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Казаклар авылыннан 2,2 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 50 нче тоташу ноктасыннан алып 50 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м көнчыгышка таба уза, «Лаеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Балык Бистәсе участок урманчылыгындагы 160 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап 30 м бара, аннары 500 м, сынык сызык ясап, әлеге урман кварталының аерымланган кишәрлеген кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба, 2,6 км көньякка таба, 500 м көньяк-көнбатышка таба һәм 750 м көньяк-көнчыгышка таба уза, алга таба «Кызыл Йолдыз урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Балык Бистәсе участок урманчылыгындагы 139 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап 30 м көньяк-көнчыгышка таба, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 139 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап 40 м, 450 м агачлык-куаклыклар массивының көнчыгыш чиге буйлап, 800 м, Олы Елга – Кама профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,0 км, урман полосасын кисеп үтеп, әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 950 м, Олы Елга – Кама профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, әлеге урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 1,4 км әлеге автомобиль юлы буйлап бара, аннары 50 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м урман утыртмаларының көнчыгыш чиге буйлап, 900 м 144 нче урман кварталының көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап уза, аннары, әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 350 м көньяк-көнбатышка таба һәм 350 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, 100 м көньяк-көнбатышка таба Олы Елга – Кама профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, алга таба 20 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары 150 м төньяк-көнчыгышка таба урман массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м 142 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м 142 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, алга таба 150 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м көньяк-көнчыгышка таба, 150 м төньяк-көнчыгышка таба, 250 м, Олы Елга – Кама профильле автомобиль юлына

бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка таба, 550 м төньяк-көнчыгышка таба, 150 м көньяк-көнчыгышка таба, 300 м төньяк-көнчыгышка таба бара, аннары 350 м төньяк-көнчыгышка таба 142 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, алга таба 100 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м көнчыгышка таба, 100 м көньяк-көнбатышка таба бара, аннары 350 м көньяк-көнбатышка таба 142 нче урман кварталы буйлап уза, алга таба 100 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба бара, алга таба, текә ярны кисеп үтеп, 100 м көньяк-көнчыгышка таба «Лаеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Балык Бистәсе участок урманчылыгындагы 142 нче урман кварталы буйлап, 2,2 км Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап сусаклагычның уң текә ярына кадәр, 53 нче тоташу ноктасына кадәр бара.»;

5) 23 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга.

**5 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 18 октябре
№ 81-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 1150. Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм референдумнар турында Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 26 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Сайлау кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 5, № 12 (I өлеш);

2010, № 6; 2011, № 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяда:

а) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына сайлауларда тавыш бирү көне – шушы органнарның яисә шушы органнар депутатларының вәкаләтләре чоры тәмамлана торган елның сентябренең икенче якшәмбесе, ә вәкаләтләре чоры чираттагы чакырылыш Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлауларны уздыру елында тәмамлана торган булса, әлеге статьяның 3, 3[1] һәм 4 өлешләрендә каралган очраклардан тыш, шушы сайлауларда тавыш бирү көне була.»;

б) 3 өлештә «, моңа Татарстан Республикасы Президентын вакытыннан алда сайлаулар керми, алар, әлеге статьяның 5 өлешендә каралган сайлауларны билгеләү срокларын исәпкә алып, вакытыннан алда шулай вәкаләтләр туктатылганнан соңгы сентябрьнең якындагы икенче якшәмбесендә уздырыла» сүзләрен өстәргә;

в) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Сайлауларда тавыш бирү бары тик якшәмбегә генә билгеләнергә мөмкин. Тавыш бирүне эш көне булмаган бәйрәм көненә, аннан алдагы көнгә, эш көне булмаган бәйрәм көненнән соңгы көнгә һәм билгеләнгән тәртиптә эш көне дип игълан ителгән якшәмбегә билгеләү рөхсәт ителми. Әгәр сентябрьнең сайлаулар билгеләнергә тиешле икенче якшәмбесе эш көне булмаган бәйрәм көненә яисә аннан алдагы көнгә, яисә эш көне булмаган бәйрәм көненнән соңгы көнгә, йә сентябрьнең икенче якшәмбесе билгеләнгән тәртиптә эш көне дип игълан ителгән булса, сайлаулар сентябрьнең өченче якшәмбесенә билгеләнә.»;

2) 11 статьяда:

а) 1 өлештә «Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлаулар турында» 2005 елның 18 маендагы 51-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – «Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлаулар турында» Федераль закон) 82[1] статьясы нигезендә депутат мандатлары тапшырылган кандидатларның федераль

исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләр» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 4[1] өлештә «Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлаулар турында» Федераль законның 82[1] статьясы нигезендә депутат мандатлары тапшырылган кандидатларның федераль исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләр һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 5 өлешнең беренче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Һәр сәяси партиянең, һәр сайлау берләшмәсенең, башка иҗтимагый берләшмәнең тәкъдиме буенча комиссиягә бер генә хәлиткеч тавыш бирү хокукына ия комиссия әгъзасы билгеләнеп куелырга мөмкин.», икенче җөмлә башында «Әлеге Кодексның 16 статьясындагы 3 өлешендә каралган очрактан тыш,» сүзләрен өстәргә;

г) 9 һәм 10 өлешләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Округ комиссияләре составы буенча тәкъдимнәр кабул итү срогы – 10 көн, башка комиссияләр составы буенча 30 көн тәшкил итә. Комиссия төзү һәм аның составына кандидатуралар буенча тәкъдимнәр кабул итү срогы турындагы хәбәр күрсәтелгән тәкъдимнәрне кабул итү башланганчыга кадәр массакүләм мәгълүмат чараларында басылып чыгарга тиеш. Мондый чакта округ комиссиясен төзү турындагы хәбәр – округ комиссиясен төзүнең әлеге Кодексның 91[1] статьясындагы 4 өлеше яисә 108[1] статьясындагы 4 өлеше нигезендә билгеләнгән иң чик срогы тәмамланырга 20 көннән дә соңга калмыйча, башка комиссия төзү турындагы хәбәр тиешле комиссиянең вәкаләтләр чоры тәмамланырга 60 көннән дә соңга калмыйча рәсми басылып чыгарга тиеш.

10. Округ комиссиясен төзү тиешле комиссия составына билгеләп кую өчен кандидатуралар турындагы тәкъдимнәр кабул итү тәмамланган көннән алып 10 көн эчендә, башка комиссияне төзү 30 көн эчендә гамәлгә ашырыла.»;

3) 12 статьяда:

а) 7 өлештәге 1 пунктта «, шулай ук «Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлаулар турында» Федераль законның 82[1] статьясы нигезендә депутат мандатлары тапшырылган кандидатларның федераль исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләр» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 10[1] өлеш өстәргә:

«10[1]. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе Татарстан Республикасы территориясендә сайлау участокларының бердәй нумерациясен билгели.»;

4) 13 статьяда:

а) 4 өлештә беренче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе вәкаләтләре бу муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы мөрәҗәгатенә нигезләнеп кабул ителгән Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары нигезендә территория комиссиясенә яисә муниципаль берәмлек чикләрендә эш итүче участок комиссиясенә йөкләнергә мөмкин.»;

б) 8 өлештәге 1 пунктта «, шулай ук «Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлаулар турында «Федераль законның 82[1] статьясы нигезендә депутат мандатлары тапшырылган кандидатларның федераль исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләр» сүзләрен төшереп калдырырга;

5) 14 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14 статья. **Округ комиссияләренең статусы һәм аларны төзү тәртибе**

1. Округ комиссияләре әлеге Кодексның 91[1] статьясындагы 1 өлешендә һәм 108[1] статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән очракларда бермандатлы һәм (яисә) күпмандатлы сайлау округлары буенча сайлаулар уздырганда тиешле бермандатлы (күпмандатлы) округларда сайлаулар уздыру һәм сайлаулар нәтиҗәләрен билгеләү өчен төзелә. Округ комиссияләренең вәкаләтләре башка сайлау комиссияләренә дә йөкләнергә мөмкин.

2. Округ комиссияләре әлеге Кодексның 91[1] һәм 108[1] статьяларында билгеләнгән тәртиптә төзелә.

3. Округ комиссияләренең вәкаләтләр чоры, әгәр шушы комиссиянең тавышларны санау тәртибен бозуга китергән гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата югарырак комиссиягә шикаятьләр (гаризалар) кермәгән булса, йә әлеге фактлар буенча суд тикшерүе алып барылмаса, сайлаулар нәтиҗәләре рәсми басылып чыккан көннән алып ике айдан соң тәмамлана. Сайлау округы территориясендә тавыш бирү йомгакларына яисә сайлаулар нәтиҗәләренә карата шикаять бирелгән очракта, округ комиссиясенең вәкаләтләре югарырак комиссия тарафыннан карар кабул ителгән көннән йә шикаять (гариза) буенча суд карары законлы көченә кергән көннән туктатыла.

4. Округ комиссияләре, әлеге статьяның 1 өлеше нигезендә округ комиссияләре вәкаләтләрен башкара торган башка комиссияләр алга таба шулай ук округ комиссияләре дип аталачак.»;

6) 15 статьяның 7 өлешендәге 1 пунктында «, шулай ук «Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлаулар турында» Федераль законның $82^1$ статьясы нигезендә депутат мандатлары тапшырылган кандидатларның федераль исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләр» сүзләрен төшереп калдырырга;

7) 16 статьяда:

а) 1 – 6 өлешләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Сайлау участокларында сайлаучыларның тавыш бирү барышын тәэмин итү һәм сайлаучыларның тавышларын санау өчен территория комиссияләре тарафыннан участок комиссияләре төзелә. Участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш бирү хокукына ия әгъзалары саны аны төзи торган территория комиссиясе тарафыннан, тиешле сайлау участогы территориясендә теркәлгән сайлаучылар санына карап, түбәндәге чикләрдә билгеләнә:

1) 1001 сайлаучыга кадәр – участок комиссиясенең 3 – 9 әгъзасы;

2) 1001дән 2001 сайлаучыга кадәр – участок комиссиясенең 7 – 12 әгъзасы;

3) 2000нән артык сайлаучы – участок комиссиясенең 7 – 16 әгъзасы.

2. Сайлауларда һәм төрле дәрәҗәдәге референдумнарда тавыш бирү көннәре туры килгән очракта, участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш бирү хокукына ия әгъзаларының әлеге статьяның 1 өлешендә каралган максималь саны территория комиссиясе тарафыннан билгеләнгән срокка участок комиссияләре составлары резервыннан арттырылырга мөмкин, әмма ул дүрттән артыграк була алмый. Бу срок, әгәр шушы участок комиссиясенең тавыш бирү тәртибен һәм (яисә) тавышларны санау тәртибен бозуга китергән гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата югарырак комиссиягә шикаятьләр (гаризалар) кермәгән булса, йә мондый фактлар буенча суд тикшерүе алып барылмаса, сайлаулар нәтиҗәләре рәсми басылып чыккан көннән алып ун көннән дә иртәрәк тәмамлана алмый. Тиешле сайлау участогында тавыш бирү йомгакларына карата шикаять бирелгән очракта, бу участок комиссиясе әгъзаларының вәкаләтләре югарырак комиссия тарафыннан карар кабул ителгән көнгә кадәр йә шикаять (гариза) буенча суд карары законлы көченә кергән көнгә кадәр озай-

тыла. Мондый чакта бу участок комиссиясе әгъзаларына хезмәт өчен өстәмә түләү (бүләкләү) һәм аларга төп эш урыныннан азат ителгән чор дәвамында компенсация түләү тиешле бюджет акчалары исәбеннән башкарыла.

3. Участок комиссиясен төзү әлеге Кодексның 11 статьясындагы 2 өлешендә күрсәтелгән тәкъдимнәргә, шулай ук муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы, яшәү, эшләү, хезмәт, уку урыны буенча сайлаучылар җыелышлары тәкъдимнәренә нигезләнеп башкарыла. Кертелә торган тәкъдимнәр саны чикләнми.

4. Территория комиссиясе түбәндәгеләрдән кергән тәкъдимнәр нигезендә участок комиссиясе әгъзаларының гомуми саныннан кимендә икедән берен билгеләп куярга тиеш:

1) Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында депутат мандатларын бүлешүгә кертелгән кандидатларның федераль исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләрдән;

2) Татарстан Республикасы Дәүләт Советында депутат мандатларын бүлешүгә кертелгән кандидатлар исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләрдән, шулай ук әлеге Кодексның $97^1$ статьясы нигезендә депутат мандатлары тапшырылган кандидатлар исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләрдән;

3) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында депутат мандатларын бүлешүгә кертелгән кандидатлар исемлекләрен күрсәткән сайлау берләшмәләреннән.

5. Әлеге статьяның 3 өлеше нигезендә участок комиссиясе составына тәкъдим ителгән, әмма комиссия әгъзалары итеп билгеләнеп куелмаган кандидатуралар Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе төзи торган участок комиссияләре составлары резервына кертеләләр.

6. Участок комиссиясенең вәкаләтләр чоры биш ел тәшкил итә. Участок комиссиясенең вәкаләтләре, сайлау участоклары исемлеген төгәлләштерүгә бәйле рәвештә сайлау участогы бетерелгән очракта, территория комиссиясе карары белән вакытыннан алда туктатыла. Әлеге статьяның 1 өлеше нигезендә төзелгән участок комиссиясенең вәкаләтләр чоры шул комиссия катнаша торган сайлау кампаниясе вакытында тәмамланса, аның вәкаләтләре чоры бу сайлау кампаниясе тәмамланганчыга кадәр озайтыла.»;

б) түбәндәге эчтәлекле $6^1$ өлеш өстәргә:

«$6^1$. Сайлаучылар вакытлыча була торган урыннарда яисә Россия Федерациясе чикләрендә яшәү урыны буенча теркәлмәгән сайлаучылар килә торган урыннарда төзелгән сайлау участогын-

да участок комиссиясе территория комиссияләре тарафыннан тавыш бирү көненә кадәр 15 көннән дә соңга калмыйча, ә аерым очракларда – тавыш бирү көненә кадәрге көннән соңга калмыйча, әлеге статьяның 5 өлешендә каралган участок комиссияләре составлары резервыннан төзелә.»;

8) 17 статьяның 8 һәм 9 өлешләрен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Территория комиссиясе рәисе үз вазыйфасына Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары белән комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары арасыннан билгеләнеп куела һәм вазыйфасыннан азат ителә.

9. Округ сайлау комиссиясе рәисе үз вазыйфасына комиссиянең югарырак комиссия карары белән хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары арасыннан билгеләнеп куела һәм вазыйфасыннан азат ителә. Участок комиссиясе рәисе үз вазыйфасына территория комиссиясе карары белән комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары арасыннан билгеләнеп куела һәм вазыйфасыннан азат ителә.»;

9) 18 статьяда:

а) 1 өлешнең 7 пунктына «, кандидатлар исемлекләре» сүзләрен өстәргә;

б) 5 өлештә «вәкаләтләре чоры» сүзләреннән соң «, әлеге Кодексның 16 статьясындагы 2 өлешендә каралган очрактан тыш,» сүзләрен өстәргә;

в) 7 өлештә «даими (штат) нигездә эшләүче» сүзләрен төшереп калдырырга, «9 пунктында» сүзләрен «9 һәм 10 пунктларында» сүзләренә алмаштырырга;

г) 10 өлештә беренче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Сайлау кампаниясе чорында комиссия әгъзасын билгеләп куйган орган әлеге статьяның 6 һәм 8 өлешләрендә күрсәтелгән сәбәпләр белән киткән комиссия әгъзасы урынына яңасын әлеге Кодексның 11–16 статьяларында билгеләнгән таләпләр нигезендә аның китү көненнән соң ун көннән дә соңга калмыйча билгеләп куярга тиеш.»; түбәндәге эчтәлекле яңа икенче җөмлә өстәргә: «Комиссия әгъзасын билгеләп куйган орган башка чорда участок комиссиясенең яңа әгъзасын – киткән комиссия әгъзасының вәкаләтләре туктатылган көннән алып өч айдан да соңга калмыйча, ә башка комиссиянең яңа әгъзасын бер айдан да соңга калмыйча билгеләп куярга тиеш.»; «Әлеге таләп» сүзләрен «Әлеге таләпләр» сүзләренә алмаштырырга; түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Участок комиссиясенең яңа әгъзасы, әлеге Кодексның

11 статьясындагы 4 һәм 4[1] өлешләрендә каралган таләпләрне үтәп, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә участок комиссияләре составлары резервыннан билгеләнеп куела.»;

д) 11 өлештә «һөнәри» сүзен төшереп калдырырга;

е) түбәндәге эчтәлекле 21 өлеш өстәргә:

«21. Хәлиткеч тавыш бирү хокукына ия комиссия әгъзаларына билгеләнгән үрнәктәге таныклыклар бирелә.»;

10) 20 статьяда:

а) 4 өлештә «, «Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлаулар турында» Федераль законның 82[1] статьясы нигезендә кандидатларның федераль исемлекләренә депутат мандатлары тапшырылган сәяси партияләр» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 9 өлештә «Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлаулар турында» Федераль законның 82[1] статьясы нигезендә кандидатларның федераль исемлекләренә депутат мандатлары тапшырылган сәяси партияләрнең,» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле 10 өлеш өстәргә:

«10. Комиссиянең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзаларына таныклыклар бирелә, аларның рәвеше Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.»;

11) 25 статьяның 2 өлешендә «төзелә» сүзе алдыннан «ун елга» сүзләрен өстәргә;

12) 26 статьяда:

а) 1 өлештәге 3 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

б) 2 – 4 өлешләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Сайлауларны оештыручы сайлау комиссиясе сайлау округларының яңа схемасын аның график сурәте белән бергә, сайлау округларының элеккеге схемасы расланган срок тәмамланырга 80 көннән дә соңга калмыйча, тиешенчә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы каравына тапшыра.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы сайлау округларының элеккеге схемасы расланган срок тәмамланырга 20 көннән дә соңга калмыйча сайлау округларының яңа схемасын раслый, бу вакытта шушы орган, сайлау округларының тәкъдим ителгән схемасы расланганчы, аңа төзәтмәләр кертергә хокуклы.

4. Әгәр сайлау округларының яңа схемасы әлеге статьяның 3 өлешендә күрсәтелгән срокта, шул исәптән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы булмау аркасында расланмаса, ул тиешле сайлауларны оештыручы сайлау комиссиясе тарафыннан әлеге статьяның 3 өлешендә күрсәтелгән срок тәмамлангач бер айдан да соңга калмыйча раслана.»;

в) түбәндәге эчтәлекле $6^1$ өлеш өстәргә:

«$6^1$. Сайлаулар уздырганда Татарстан Республикасы Конституциясенең, Татарстан Республикасы законының, муниципаль берәмлек уставының тиешенчә Дәүләт Советы депутатлары, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатлары санын һәм (яисә) тиешле сайлауларда кулланыла торган сайлау системасы төрен билгели торган нигезләмәләренең үзгәрүенә бәйле рәвештә, шулай ук муниципаль берәмлекнең чикләре үзгәрүгә бәйле рәвештә тиешенчә бермандатлы һәм (яисә) күпмандатлы сайлау округларының схемасын куллану мөмкин булмаса, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы, сайлауларны оештыра торган сайлау комиссиясе тәкъдиме белән, Татарстан Республикасы Конституциясенең, Татарстан Республикасы законының, муниципаль берәмлек уставының тиешле нигезләмәләре үз көченә кергән көннән алып 30 көннән соңга калмыйча бермандатлы һәм (яисә) күпмандатлы сайлау округларының яңа схемасын расларга хокуклы. Әгәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы бермандатлы һәм (яисә) күпмандатлы сайлау округларының яңа схемасын күрсәтелгән срокта, шул исәптән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы булмау сәбәпле, расламаса, мондый схеманы, күрсәтелгән срок тәмамланганнан соң 10 көннән дә соңга калмыйча, сайлауларны оештыра торган сайлау комиссиясе раслый.»;

13) 27 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«27 статья. **Сайлау участокларын төзү**

1. Тавыш бирүне уздыру һәм сайлаучыларның тавышларын санау өчен сайлау участоклары төзелә. Сайлау участоклары Татарстан Республикасы территориясендә уздырыла торган барлык сайлаулар өчен бертөрле була.

2. Сайлау участоклары, «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 16 статьясындагы 10 пункты нигезендә сайлау участогы территориясендә теркәлгән сайлаучылар саны турындагы белешмәләр нигезендә сайлаучылар өчен максималь уңайлыклар булдыру зарурлыгыннан чыгып, җирле һәм башка шартларны исәпкә алып, түбәндәге таләпләрне үтәгән килеш биш елга төзелә:

1) сайлау участогы территориясендә иң күбе өч мең сайлаучы теркәлгән булырга тиеш;

2) сайлау округларының чикләре сайлау участоклары чикләре белән кисешмәскә тиеш.

3. Сайлау участоклары, тиешле территория комиссиясе белән килештереп, муниципаль район, шәһәр округының җирле администрациясе башлыгы тарафыннан төзелә. Әгәр сайлаучыларны теркәү (исәпкә алу) белешмәләре буенча участоктагы сайлаучылар саны 3100дән артыграк булса йә әлеге статьяның 2 өлешендәге 2 пункты бозылса, сайлау участокларының исемлеге һәм аларның чикләре аларны төзү өчен каралган тәртиптә төгәлләштерелергә тиеш. Сайлау участокларының исемлеге һәм аларның чикләре муниципаль берәмлекләрнең чикләре үзгәртелүгә, муниципаль берәмлекләр үзгәртеп корылуга, бетерелүгә, сайлау участогы территориясендә теркәлгән сайлаучыларның саны кимүгә (50гә кадәр һәм аннан кимрәккә) бәйле рәвештә дә шушы тәртиптә төгәлләштерелергә мөмкин.

4. Сайлаучылар вакытлыча була торган урыннарда (хастаханәләрдә, шифаханәләрдә, ял йортларында, вокзалларда, аэропортларда, шик белдерелгән һәм гаепләнүче затларны сак астында тоту урыннарында һәм вакытлыча була торган башка урыннарда) сайлау участоклары территория комиссиясе (муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе) тарафыннан ул билгеләгән срокка, тавыш бирү көненә кадәр 30 көннән дә соңга калмыйча, ә аерым очракларда тавыш бирү көненә кадәр өч көннән дә соңга калмыйча (Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына сайлаулар уздырганда шулай ук Татарстан Республикасы

Үзәк сайлау комиссиясе белән дә килештереп) төзелергә мөмкин. Мондый участоклар сайлау округларына аларның урнашу урыны буенча кертеләләр.

5. Сайлау участокларының исемлекләре, аларның чикләрен (әгәр сайлау участогы торак пункт территориясенең бер өлешендә төзелгән булса) йә торак пунктларның исемлеген (әгәр сайлау участогы бер яисә берничә торак пункт территориясендә төзелгән булса), участок комиссияләренең номерларын, урнашкан урыннарын һәм тавыш бирү биналарын күрсәтеп, – муниципаль район, шәһәр округы администрациясе башлыгы тарафыннан, ә җирлекнең җирле үзидарә органына сайлаулар уздырганда җирлек администрациясе башлыгы тарафыннан тавыш бирү көненә кадәр 40 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарылырга тиеш. Сайлаучылар вакытлыча була торган урыннарда (хастаханәләрдә, шифаханәләрдә, ял йортларында, вокзалларда, аэропортларда, шик белдерелгән һәм гаепләнүче затларны сак астында тоту урыннарында һәм вакытлыча була торган башка урыннарда) төзелгән сайлау участоклары турындагы мәгълүмат шушы учреждениеләрнең администрацияләре тарафыннан сайлаучыларга җиткерелә һәм, алар төзелгәннән соң ике көннән дә соңга калмыйча, территория комиссиясе (муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе) тарафыннан бастырып чыгарылырга тиеш.»;

14) 28 статьяда:

а) 2 өлештә «тавыш бирү көненә кадәр 21 көннән дә соңга калмыйча» сүзләрен «тавыш бирү көненә кадәр 11 көннән дә соңга калмыйча» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 өлештә «тавыш бирү көненә кадәр 20 көннән дә соңга калмыйча» сүзләрен «тавыш бирү көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча» сүзләренә алмаштырырга;

в) 11 өлештә «тавыш бирү көненә кадәр 20 көннән дә соңга калмыйча» сүзләрен «тавыш бирү көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча» сүзләренә алмаштырырга;

15) 30 статьяның 1 өлешендә «20 көн кала» сүзләрен «10 көн кала» сүзләренә алмаштырырга;

16) 39 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ – $1^3$ өлешләр өстәргә:

«$1^1$. Дәүләт Советы депутатларын сайлауларны, муниципаль районнарның башлыкларын һәм шәһәр округлары башлыкларын сайлауларны уздырганда кандидат сайлау комиссиясенә

шулай ук Россия Федерациясе Президенты указы белән каралган форма буенча түбәндәгеләрне тапшыра:

1) кандидатка, аның хатынына (иренә) һәм балигъ булмаган балаларына карый торган Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан күчемсез мөлкәт турында, шул мөлкәт сатып алынган акчаларны алу чыганаклары хакында, кандидатның Россия Федерациясе территориясеннән читтә мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының шундый йөкләмәләре хакында белешмәләрне;

2) җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар) сатып алуга кагылышлы алыш-биреш буенча үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары һәм, әгәр алыш-биреш суммасы кандидатның һәм аның хатынының (иренең) алыш-биреш башкарылганчыга кадәр соңгы өч елдагы гомуми керемennән артса, алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләрне.

$1^2$. Әлеге статьяның $1^1$ өлешендә күрсәтелгән белешмәләрне тикшерү тәртибе Россия Федерациясе Президенты указы белән билгеләнә.

$1^3$. Дәүләт Советы депутатларын сайлауларны уздырганда кандидат үзенең теркәлү вакытына Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларындагы счетларын (кертемнәрен) ябарга, акчалар һәм кыйммәтле әйберләрен саклауны туктатырга һәм (яисә) чит ил финанс инструментларыннан читләшерүне гамәлгә ашырырга тиеш.»;

б) 3 өлештә «1 өлешендә каралган» сүзләрен «1 һәм $1^1$ өлешләрендә каралган» сүзләренә алмаштырырга;

17) 40 статьяга түбәндәге эчтәлекле $3^2$ һәм $3^3$ өлешләр өстәргә:

«$3^2$. Дәүләт Советы депутатларын сайлауларны уздырганда кандидат сайлау комиссиясенә шулай ук Россия Федерациясе Президенты указы белән каралган рәвештә әлеге Кодексның 39 статьясындагы $1^1$ өлешендә күрсәтелгән белешмәләрне тапшыра.

$3^3$. Дәүләт Советы депутатларын сайлауларны уздырганда кандидат үзенең теркәлү вакытына Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларындагы счетларын (кертемнәрен) ябарга, акчалар һәм кыйммәтле әйберләрне

саклауны туктатырга һәм (яисә) чит ил финанс инструментларыннан читләшерүне гамәлгә ашырырга тиеш.»;

18) 41 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $1^2$ һәм $1^3$ өлешләр өстәргә:

«$1^2$. Дәүләт Советы депутатларын сайлауларны уздырганда кандидат сайлау комиссиясенә шулай ук Россия Федерациясе Президенты указы белән каралган рәвештә әлеге Кодексның 39 статьясындагы $1^1$ өлешендә күрсәтелгән белешмәләрне тапшыра.

$1^3$. Дәүләт Советы депутатларын сайлауларны уздырганда кандидат үзенең теркәлү вакытына Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларындагы счетларын (кертемнәрен) ябарга, акчалар һәм кыйммәтле әйберләрен саклауны туктатырга һәм (яисә) чит ил финанс инструментларыннан читләшерүне гамәлгә ашырырга тиеш.»;

б) 4 өлештә «Әлеге статьяның 1 өлешендә» сүзләреннән соң «һәм әлеге Кодексның 39 статьясындагы $1^1$ өлешендә» сүзләрен өстәргә;

19) 42 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ һәм $2^2$ өлешләр өстәргә:

«$2^1$. Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны, муниципаль районнар башлыкларын һәм шәһәр округлары башлыкларын сайлауларны уздырганда кандидат сайлау комиссиясенә шулай ук Россия Федерациясе Президенты указы белән каралган рәвештә әлеге Кодексның 39 статьясындагы $1^1$ өлешендә күрсәтелгән белешмәләрне тапшыра.

$2^2$. Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны, муниципаль районнар башлыкларын һәм шәһәр округлары башлыкларын сайлауларны уздырганда кандидат үзенең теркәлү вакытына Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларындагы счетларын (кертемнәрен) ябарга, акчалар һәм кыйммәтле әйберләрен саклауны туктатырга һәм (яисә) чит ил финанс инструментларыннан читләшерүне гамәлгә ашырырга тиеш.»;

б) 4 өлештә «Әлеге статьяның 1 һәм 2 өлешләрендә» сүзләреннән соң «, шулай ук әлеге Кодексның 39 статьясындагы $1^1$ өлешендә» сүзләрен өстәргә;

20) 45 статьяда:

а) 3 өлештә:

беренче абзацта «тапшырыла» сүзе алдыннан «язма рәвештә» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле 3 – 5 пунктлар өстәргә:

«3) Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Федерация Советы әгъзасы – Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы вәкиле вәкаләтләрен бирү өчен кандидатларга карата (алга таба – Федерация Советы әгъзасы вәкаләтләрен бирү өчен кандидат, кандидатура) федераль законда каралган таләпләргә туры килә торган өч кандидатура турындагы белешмәләр, аларда түбәндәгеләр күрсәтелергә тиеш:

а) фамилиясе, исеме, атасының исеме;

б) туу датасы;

в) әлеге затның яшәү урыны урнашкан Россия Федерациясе субъектының, районның, шәһәрнең, башка торак пунктның исеме;

г) төп эш яисә хезмәт урыны, били торган вазыйфасы (төп эш яисә хезмәт урыны булмаганда – шөгыльләренең төре);

4) Федерация Советы әгъзасы вәкаләтләрен бирү өчен кандидатларның һәркайсыннан, Федерация Советы әгъзасы вәкаләтләре бирелгән очракта, Федерация Советы әгъзасы статусына туры килми торган эшчәнлеген туктату йөкләмәсе белән Федерация Советы әгъзасы вәкаләтләрен бирү өчен кандидатура буларак тәкъдим ителүгә аның ризалыгы турында гариза. Гариза кире алынмый, анда шушы зат турында түбәндәге белешмәләр күрсәтелә:

а) фамилиясе, исеме, атасының исеме;

б) туу датасы һәм урыны;

в) яшәү урыны адресы, шулай ук гариза язылган датага кадәрге биш ел дәвамында яшәү урыны адресы турындагы белешмәләр;

г) граждан паспортының яисә паспортын алыштыра торган документының сериясе, номеры һәм бирү датасы, паспорт яисә граждан паспортын алыштыра торган документ биргән органның исеме яисә коды;

д) гражданлыгы;

е) төп эш яисә хезмәт урыны, били торган вазыйфасы (төп эш яисә хезмәт урыны булмаганда – шөгыльләренең төре), шулай ук Федерация Советы әгъзасы вәкаләтләрен бирү өчен кандидат итеп күрсәтелгәнгә кадәр тулаем алганда биш ел били торган дәүләт вазыйфалары яисә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары турында белешмәләр;

ж) Федерация Советы әгъзасы вәкаләтләрен бирү өчен федераль закон нигезендә каршы килә торган чикләүләр булмау турында мәгълүмат;

5) әлеге өлешнең 4 пунктында күрсәтелгән белешмәләрне раслый торган документларның күчермәләре.»;

б) түбәндәге эчтәлекле $3^1$ өлеш өстәргә:

«$3^1$. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына сайлауларны, муниципаль районнар башлыкларын һәм шәһәр округлары башлыкларын сайлауларны уздырганда кандидат сайлауларны оештыра торган сайлау комиссиясенә кандидатны теркәү өчен кирәкле башка документлар белән бергә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетларының (кертемнәренең) булмавы, акчалар һәм кыйммәтле әйберләрне сакламавы, чит ил финанс инструментларына ия булмавы һәм (яисә) алардан файдаланмавы турында язма хәбәрнамә тапшыра.»;

21) 46 статьяда:

а) 4 өлештә «әлеге Кодексның 39 – 42 статьялары нигезендә кандидатлар турында тапшырыла торган белешмәләрнең» сүзләреннән соң «, шулай ук Федерация Советы әгъзасы вәкаләтләрен бирү өчен кандидатуралар турында Татарстан Республикасы Президенты вазыйфасына кандидат тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрнең» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле $4^1$ өлеш өстәргә:

«$4^1$. Әлеге Кодексның 39 статьясындагы $1^3$ өлешендә, 40 статьясындагы $3^3$ өлешендә, 41 статьясындагы $1^3$ өлешендә һәм 42 статьясындагы $2^2$ өлешендә каралган таләпләрнең үтәлешен тикшерү «Аерым категорияләрдәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» Федераль законда билгеләнгән нигезләр буенча гамәлгә ашырыла.»;

в) 9 өлештә «цифрлы» сүзен төшереп калдырырга;

22) 47 статьяда:

а) 2 өлештә «закон таләпләренә туры килүен» сүзләреннән соң «, ә Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны уздырганда – шулай ук әлеге Кодексның $104^5$ статьясындагы 2 өлешендә каралган таләпләрнең үтәлешен» сүзләрен өстәргә;

б) 6 өлешкә түбәндәге эчтәлекле $1^1$ һәм $1^2$ пунктлар өстәргә:

«$1^1$) Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны уздырганда – Федерация Советы әгъзасы вәкаләтләрен бирү өчен кандидатуралар турында кандидат тарафыннан бирелгән белешмәләрне тапшырмау;

$1^2$) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына сайлауларны, муниципаль районнар башлыкларын һәм шәһәр округлары башлыкларын сайлауларны уздырганда – кандидатның әлеге Кодексның 39 статьясындагы $1^3$ өлешендә, 41 статьясындагы $1^3$ өлешендә һәм 42 статьясындагы $2^2$ өлешендә билгеләнгән таләпләрне үтәмәве;»;

в) 8 өлешкә түбәндәге эчтәлекле $3^1$ пункт өстәргә:

«$3^1$) Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауларны уздырганда – кандидатның әлеге Кодексның 40 статьясындагы $3^3$ өлешендә билгеләнгән таләпләрне үтәмәве;»;

г) 11 өлештә «кичектерелә» сүзе алдыннан «өч айдан артыграк булмаган срокка» сүзләрен өстәргә, икенче җөмләне төшереп калдырырга;

23) 66 статьяга түбәндәге эчтәлекле 12 һәм 13 өлешләр өстәргә:

«12. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына сайлауларны уздырганда, шулай ук сайлаучыларның саны ике йөз мең кешедән арткан муниципаль берәмлекләрдә җирле үзидарә органнарына сайлаулар уздырганда кулланыла торган бюллетеньнәрне, бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыкларын, махсус билгеләр (маркалар) эшләүгә заказларны урнаштыру тиешле сайлауларны оештыра торган комиссия тарафыннан яисә түбәнгерәк тиешле комиссияләр карары нигезендә «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законда каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

13. Сайлауларны әзерләүгә һәм уздыруга бәйле товарлар кайтаруга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштыру комиссияләр тарафыннан тиешле бюджетның расланган бюджет язмасы нигезендә сайлауларны билгеләү турындагы карар рәсми бастырып чыгарылган көнгә кадәр гамәлгә ашырылырга мөмкин.»;

24) 72 статьяның 1 өлешендә «1 өлешенең 3 пункты» сүзләрен «1 өлешенең 3 пункты һәм $1^1$ өлеше» сүзләренә алмаштырырга, «керемнәре һәм аларның чыганаклары турында» сүзләрен «керемнәре һәм аларның чыганаклары турында һәм чыгымнары хакында» сүзләренә алмаштырырга, «дөреслеген» сүзеннән соң «, кандидатлар тарафыннан 39 статьяның $1^3$ өлешендә, 40 статьяның $3^3$ өлешендә, 41 статьяның $1^3$ өлешендә һәм 42 статьяның $2^2$ өлешендә каралган таләпләрнең үтәлүен» сүзләрен өстәргә;

25) 73 статьяга түбәндәге эчтәлекле 3[1] өлеш өстәргә:

«3[1]. Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны уздырганда участок комиссиясе мәгълүмат стендында Федерация Советы әгъзасы вәкаләтләрен бирү өчен кандидатуралар турында Татарстан Республикасы Президенты вазыйфасына кандидатлар тарафыннан тапшырылган әлеге Кодексның 45 статьясындагы 3 өлешенең 3 пунктында каралган белешмәләрне урнаштыра. Күрсәтелгән белешмәләр булган мәгълүмати материаллар шулай ук участок комиссиясе тарафыннан һәр сайлаучының үзенә дә бирелергә мөмкин.»;

26) 74 статьяның 9 өлешендә «20 көн алдан» сүзләрен «10 көн алдан» сүзләренә алмаштырырга;

27) 76 статьяда:

а) 2 өлештә «20 көннән» сүзләрен «10 көннән» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 өлештә «тавыш бирү башланыр алдыннан» сүзләрен «тавыш бирү вакыты җитәр алдыннан гына» сүзләренә алмаштырырга, «сайлаучыларга,» сүзен төшереп калдырырга, «(пломба салына)» сүзләрен өстәргә;

в) түбәндәге эчтәлекле 17 өлеш өстәргә:

«17. Сайлаулар уздырганда кәгазьдә әзерләнгән бюллетеньнәр кулланып тавыш бирү урынына электрон тавыш бирү уздырылырга мөмкин. Электрон тавыш бирүне уздыру турында карар Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан яисә аның кушуы буенча Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан кабул ителә. Электрон тавыш бирү, сайлаучыларның тавышларын санау һәм сайлау участогында тавыш бирү йомгакларын билгеләү тәртибе, тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссиясе беркетмәсенең рәвеше, шулай ук югарырак комиссияләр тарафыннан, электрон тавыш бирү йомгакларын исәпкә алып, тавыш бирү йомгакларын билгеләү һәм сайлаулар нәтиҗәләрен ачыклау үзенчәлекләре Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.»;

28) 77 статьяда:

а) 5 өлештә беренче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Әлеге статьяның 4 өлешендә күрсәтелгән гаризалар (телдән мөрәҗәгатьләр) тавыш бирү көненә кадәр 10 көн дәвамында теләсә кайсы вакытта, әмма тавыш бирү вакыты тәмамланырга алты сәгатьтән дә соңга калмыйча тапшырылырга мөмкин.»

б) 9 өлештә түбәндәге эчтәлекле дүртенче яңа җөмлә өстәргә: «Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны уздырганда участок комиссиясенең тавыш бирүне тавыш бирү бинасыннан читтә уздыручы хәлиткеч тавыш бирү хокукына ия әгъзаларында шулай ук әлеге Кодексның 45 статьясындагы 3 өлешенең 3 пунктында каралган белешмәләр кергән мәгълүмати материаллар булырга тиеш.».

29) 78 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ өлеш өстәргә:

«$1^1$. Тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә электрон рәвештә төзелергә мөмкин.»;

б) 2 өлешнең беренче абзацындагы беренче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә кәгазьдә рәсмиләштерелгән очракта, бер биттә төзелергә тиеш.»;

в) 5 өлешнең 4 пунктына «(кәгазьдә төзелгән беркетмә өчен)» сүзләрен өстәргә;

30) 79 статьяда:

а) 28 өлешкә түбәндәге эчтәлекле яңа икенче һәм өченче җөмләләр өстәргә: «Әгәр беркетмә электрон рәвештә төзелгән булса, аның күчермәсе беркетмәне кәгазьдә чыгарып алу юлы белән әзерләнә һәм «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законда билгеләнгән тәртиптә таныклана. Беркетмәләрнең бирелә торган таныкланган күчермәләренә номер сугыла.»;

б) 30 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«30. Тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнеү икенче нөсхәсе танышу өчен күзәтүчеләргә, әлеге Кодексның 21 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән башка затларга тапшырыла, ә аның таныкланган күчермәсе гомуми танышу өчен участок комиссиясе билгеләгән урынга элеп куела. Әгәр беркетмә электрон рәвештә төзелгән булса, аның икенче нөсхәсе беркетмәне кәгазьдә чыгарып алу юлы белән әзерләнә һәм тавыш бирү йомгакларын билгеләгәндә һәм беркетмә төзегәндә участок комиссиясенең шунда булган хәлиткеч тавыш хокукына ия барлык әгъзалары тарафыннан имзалана. Беркетмәнең икенче нөсхәсе законда каралган сайлау документациясе белән бергә, бюллетеньнәрне, участок комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзаларының, әлеге Кодексның 21 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән баш-

ка затларның исемлекләрен дә кертеп, шулай ук участок комиссиясе мөһере саклау өчен югарырак комиссиягә тапшырыла.»;

31) түбәндәге эчтәлекле 91[1] статья өстәргә:

«91[1] статья. **Дәүләт Советы депутатларын сайлаулар буенча округ комиссияләрен төзү тәртибе**

1. Округ комиссиясе һәр бермандатлы сайлау округында төзелә.

2. Округ комиссиясен төзү әлеге Кодексның 11 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән тәкъдимнәр, шулай ук муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары тәкъдимнәре, сайлаучыларның яшәү, эшләү, хезмәт итү, уку урыны буенча җыелышлары тәкъдимнәре нигезендә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан башкарыла.

3. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе округ комиссиясе әгъзаларының гомуми саныннан кимендә икедән берен түбәндәгеләрдән кергән тәкъдимнәр нигезендә билгеләп куярга тиеш:

1) Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында депутат мандатларын бүлешүгә кертелгән кандидатларның федераль исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләрдән;

2) Татарстан Республикасы Дәүләт Советында депутат мандатларын бүлешүгә кертелгән кандидатлар исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләрдән, шулай ук әлеге Кодексның 97[1] статьясы нигезендә депутат мандатлары тапшырылган кандидатлар исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләрдән.

4. Округ комиссиясе тавыш бирү көненә кадәр 75 көннән дә соңга калмыйча хәлиткеч тавыш бирү хокукына ия 9 – 13 әгъзадан төзелә.»;

32) 93 статьяның 7 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

33) 102 статьяда:

а) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әгәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советына төп сайлаулар сентябрьнең икенче якшәмбесендә уздырылса һәм аларның нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тулы хокуклы составта оешмаса, кабат сайлаулар төп сайлауларда тавыш бирү көненнән өч айдан да соңга калмыйча уздырыла. Калган очракларда кабат сайлаулар сентябрьнең икенче якшәмбесендә,ә чираттагы чакырылыш Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлауларны уздыру елында – шушы сайлауларда тавыш бирү көнендә йә башка көндә, әмма кабат сай-

лаулар уздыру өчен нигез барлыкка килгән көннән бер елдан да соңга калмыйча уздырыла.»;

б) 4 өлештә «һәм участок комиссияләренең» сүзләрен «комиссияләренең, шулай ук әлеге Кодексның 16 статьясындагы $6^1$ өлешендә күрсәтелгән участок комиссияләренең,» сүзләренә алмаштырырга;

34) 104 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Өстәмә сайлаулар сентябрьнең икенче якшәмбесенә, ә чираттагы чакырылыш Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлауларны уздыру елында – шушы сайлауларда тавыш бирү көненә билгеләнә. Әгәр өстәмә сайлаулар, шул исәптән әлеге Кодексның 87 статьясындагы 1 өлешендә каралган срокларны исәпкә алып, сентябрьнең икенче якшәмбесенә билгеләнә алмаса, алар бермандатлы сайлау округы буенча сайланган депутатның вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган көннән бер елдан да соңга калмыйча уздырылырга тиеш. Әгәр депутат вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату сәбәпле Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тулы хокуклы составында калмаса, өстәмә сайлаулар вәкаләтләрне шулай вакытыннан алда туктаткан көннән дүрт айдан да соңга калмыйча уздырыла, мондый чакта сайлау гамәлләренең сроклары Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары белән өчтән бергә кыскартылырга мөмкин.»;

35) $104^2$ статьяның 2 өлешен үз көчен югалткан дип танырга;

36) $104^5$ статьяда түбәндәге эчтәлекле 11 – 14 өлешләр өстәргә:

«11. Федерация Советы әгъзасы вәкаләтләрен бирү өчен бер үк кандидатура Татарстан Республикасы Президенты вазыйфасына бер генә кандидат тарафыннан тәкъдим ителергә мөмкин. Әгәр Федерация Советы әгъзасы вәкаләтләрен бирү өчен бер үк кандидатура төрле кандидатлар тарафыннан тәкъдим ителгән булса, ул аны элегрәк тәкъдим иткән кандидат тарафыннан тәкъдим ителгән дип санала. Әгәр тәкъдим ителгән кандидатура элегрәк башка кандидат тарафыннан тәкъдим ителгән булса, кандидат теркәлүгә кадәр Федерация Советы әгъзасы вәкаләтләрен бирү өчен өстәмә рәвештә кандидатура тәкъдим итәргә хокуклы.

12. Федерация Советы әгъзасы вәкаләтләрен бирү өчен кандидат тавыш бирү көненә кадәр 15 көннән дә соңга калмыйча төшеп калган очракта, Татарстан Республикасы Президенты вазыйфасына теркәлгән кандидат ике көн эчендә, Татарстан Респуб-

ликасы Үзәк сайлау комиссиясенә әлеге Кодексның 45 статьясындагы 3 өлешенең 3 – 5 пунктларында каралган документларны тапшырып, Федерация Советы әгъзасы вәкаләтләрен бирү өчен яңа кандидатура (яңа кандидатуралар) тәкъдим итәргә хокуклы.

13. Әлеге статьяның 14 өлешендә күрсәтелгән мәҗбүр итә торган хәлләр булганда, Татарстан Республикасы Президенты вазыйфасына теркәлгән кандидат тавыш бирү (шул исәптән кабат тавыш бирү) көненә кадәр бер көннән дә соңга калмыйча Федерация Советы әгъзасы вәкаләтләрен бирү өчен Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә тәкъдим ителгән кандидатураны чакыртып алу турында Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә язма гариза тапшырырга хокуклы.

14. Федерация Советы әгъзасы вәкаләтләрен бирү өчен үзе тәкъдим иткән кандидатураны Татарстан Республикасы Президенты вазыйфасына кандидат тарафыннан чакыртып алырга мәҗбүр итә торган хәлләр дигәндә кандидатура итеп күрсәтелгән затның вафат булуы, әлеге затның хокуктан файдалануга сәләтлелеге суд тарафыннан чикләнү, Федерация Советы әгъзасы вәкаләтләрен бирү өчен кандидатларга карата федераль законда билгеләнгән чикләүләргә бәйле хәлләр барлыкка килү аңлашыла.»;

37) $104^9$ статьяның 7 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

38 ) $104^{16}$ статьяда:

а) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әгәр Татарстан Республикасы Президентын төп сайлаулар сентябрьнең икенче якшәмбесендә уздырылса һәм аларның нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Президенты сайланмаса, кабат сайлаулар төп сайлауларда тавыш бирү көненнән өч айдан да соңга калмыйча уздырыла. Калган очракларда кабат сайлаулар – сентябрьнең икенче якшәмбесендә, ә чираттагы чакырылыш Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлауларны уздыру елында – шушы сайлауларда тавыш бирү көнендә йә башка көндә, әмма кабат сайлаулар уздыру өчен нигез барлыкка килгән көннән бер елдан да соңга калмыйча уздырыла.»;

б) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасы Президентын кабат сайлаулар әлеге Кодексның 16 статьясындагы $6^1$ өлешендә күрсәтелгән участок комиссияләренең вәкаләтләре чоры беткәнче билгеләнгән булса, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе йә участок комиссияләренең вәкаләтләре чорын озайту турында, йә участок комиссияләрен яңа составта төзү турында күрсәтмә бирергә тиеш.»;

39) 108 статьяның 10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10) округ комиссияләрен төзи һәм аларның рәисләрен билгеләп куя;»;

40) түбәндәге эчтәлекле 108[1] статья өстәргә:

«108[1] статья. **Җирле үзидарә органнарына сайлаулар буенча округ комиссияләрен төзү тәртибе**

1. Округ комиссиясе муниципаль берәмлекнең тиешле сайлау комиссиясе карары белән һәр бермандатлы (күпмандатлы) сайлау округында төзелә.

2. Округ комиссиясен төзү әлеге Кодексның 11 статьясындагы 1 һәм 2 өлешләрендә күрсәтелгән тәкъдимнәр, шулай ук муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары тәкъдимнәре, сайлаучыларның яшәү, эшләү, хезмәт, уку урыны буенча җыелышлары тәкъдимнәре нигезендә муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе тарафыннан башкарыла.

3. Муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе җирле үзидарә органнарына сайлаулар буенча округ комиссиясе әгъзаларының гомуми саныннан кимендә икедән берен түбәндәгеләрдән кергән тәкъдимнәр нигезендә билгеләп куярга тиеш:

1) Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында депутат мандатларын бүлешүгә кертелгән кандидатларның федераль исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләрдән;

2) Татарстан Республикасы Дәүләт Советында депутат мандатларын бүлешүгә кертелгән кандидатлар исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләрдән, шулай ук әлеге Кодексның 97[1] статьясы нигезендә депутат мандатлары тапшырылган кандидатлар исемлекләрен чыгарган сәяси партияләрдән;

3) тиешле муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында депутат мандатларын бүлешүгә кертелгән кандидатлар исемлекләрен күрсәткән сайлау берләшмәләреннән.

4. Округ комиссиясе тавыш бирү көненә кадәр 60 көннән дә соңга калмыйча хәлиткеч тавыш бирү хокукына ия 5 – 11 әгъзадан төзелә.»;

41) 111 статьяның 1 өлешендә «һәм (яисә күпмандатлы)» сүзләрен төшереп калдырырга;

42) 123 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Өстәмә сайлаулар сентябрьнең икенче якшәмбесенә, ә чираттагы чакырылыш Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлауларны уздыру елында – шушы сайлауларда тавыш бирү көненә билгеләнә. Әгәр өстәмә сайлаулар, шул исәптән әлеге Кодексның 105 статьясындагы 1 өлешендә каралган срокларны исәпкә алып, сентябрьнең икенче якшәмбесенә билгеләнә алмаса, алар бермандатлы сайлау округы буенча сайланган депутатның вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган көннән бер елдан да соңга калмыйча уздырылырга тиеш. Әгәр депутатларның, муниципаль берәмлекнең сайланулы органы әгъзаларының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату сәбәпле тиешле сайланулы орган хокукка ия булмаган составта калса, өстәмә сайлаулар вәкаләтләрне шулай вакытыннан алда туктаткан көннән дүрт айдан да соңга калмыйча уздырыла, мондый чакта сайлау гамәлләренең сроклары муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе карары белән өчтән бергә кыскартылырга мөмкин.»;

43) 126 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Муниципаль берәмлекнең сайланулы вазыйфаи заты вазыйфасына теркәлгән кандидатны сайланган дип тану шартларының түбәндәгеләрдән берәрсе муниципаль берәмлек уставы белән билгеләнә:

1) тавыш бирүдә катнашкан сайлаучыларның иң күп тавышын алган кандидат сайланган дип таныла;

2) иң күп тавыш алган, әмма тавыш бирүдә катнашкан сайлаучылар тавышларының билгеләнгән санынннан кимендә 25 процент тавыш алган кандидат сайланган дип таныла.»;

44) 129 статьяда:

а) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әгәр муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатларын, муниципаль берәмлекнең сайланулы органы әгъзаларын төп сайлаулар йә муниципаль берәмлекнең сайланулы вазыйфаи затын төп сайлаулар сентябрьнең икенче якшәмбесендә уздырылса һәм аларның нәтиҗәләре буенча муниципаль берәмлекнең сайланулы органы тулы хокуклы составта оешмаса йә муниципаль берәмлекнең сайланулы вазыйфаи заты сайланмаса, кабат сайлау-

лар төп сайлауларда тавыш бирү көненнән өч айдан да соңга калмыйча уздырыла. Калган очракларда кабат сайлаулар – сентябрьнең икенче якшәмбесендә, ә чираттагы чакырылыш Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлауларны уздыру елында – шушы сайлауларда тавыш бирү көнендә йә башка көндә, әмма кабат сайлаулар уздыру өчен нигез барлыкка килгән көннән бер елдан да соңга калмыйча уздырыла.»;

б) 4 өлештә «һәм участок комиссияләренең» сүзләрен «комиссияләренең, шулай ук әлеге Кодексның 16 статьясындагы $6^1$ өлешендә күрсәтелгән участок комиссияләренең» сүзләренә алмаштырырга;

45) 130 статьяда «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауларда һәм муниципаль» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

«Татарстан Республикасы референдумы турында» 2003 елның 9 августындагы 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 8; 2005, № 3 (I өлеш); 2008, № 6; 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 15 статьяның 4 пунктындагы икенче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Тавыш бирүне эш көне булмаган бәйрәм көненә, аннан алдагы көнгә, эш көне булмаган бәйрәм көненнән соңгы көнгә һәм билгеләнгән тәртиптә эш көне дип игълан ителгән якшәмбегә билгеләү рөхсәт ителми.»;

2) 16 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Референдум әзерләүне һәм уздыруны түбәндәге референдум комиссияләре башкаралар:

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе;

территория (район, шәһәр һәм башка) комиссияләре;

участок комиссияләре.»;

3) 17 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17 статья. **Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең вәкаләтләре**

Референдум әзерләгәндә һәм уздырганда Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе:

а) Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның референдумда катнашу хокукының үтәлешен тикшереп тора;

б) әлеге Законны куллану мәсьәләләре буенча инструкцияләр һәм башка норматив актлар чыгара;

в) түбәнгерәк референдум комиссияләренең эшчәнлегенә җитәкчелек итә, аларга хокукый, методик, оештыру-техник ярдәм күрсәтә;

г) инициатив төркемне терки;

д) референдумда тавыш бирү бюллетене рәвешен һәм текстын, шулай ук референдумда катнашучылар исемлегенең һәм референдум әзерләүгә, уздыруга бәйле башка документларның рәвешен раслый;

е) референдумда тавыш бирү өчен башка референдум участогында тавыш бирү таныклыгы рәвешен раслый, референдумда тавыш бирү өчен башка референдум участогында тавыш бирү таныклыкларын әзерләүне тәэмин итә һәм аларны территория комиссияләренә тапшыра;

ж) түбәнгерәк референдум комиссияләре мөһерләренең үрнәкләрен раслый;

з) референдум әзерләүне һәм уздыруны, референдум комиссияләренең эшчәнлеген финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелгән акчаларны бүлә, күрсәтелгән акчаларның максатчан кулланылуын тикшереп тора;

и) түбәнгерәк референдум комиссияләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләрне (гаризаларны) карый һәм шикаятьләр (гаризалар) буенча дәлилле карарлар кабул итә;

к) референдумда катнашучыларны референдум әзерләү һәм уздыру турындагы мәгълүмат белән тәэмин итә;

л) референдум комиссияләрен биналар, транспорт чаралары һәм элемтә чаралары белән тәэмин итүне тикшереп тора, референдумны матди-техник тәэмин итүнең башка мәсьәләләрен карый;

м) референдум әзерләүгә һәм уздыруга бәйле мәсьәләләр буенча дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлек итә;

н) федераль законнарда, әлеге Законда, башка законнарда билгеләнгән бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.»;

4) 18 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18 статья. **Территория комиссияләренең вәкаләтләре**

Референдум әзерләгәндә һәм уздырганда территория комиссиясе:

а) тиешле территориядә гражданнарның референдумда катнашу хокукының үтәлешен тикшереп тора;

б) участок комиссияләренең эшчәнлеген координацияли, аларга хокукый, методик, оештыру-техник ярдәм күрсәтә;

в) участок комиссияләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаятьләрне (гаризаларны) карый һәм шикаятьләр (гаризалар) буенча дәлилле карарлар кабул итә;

г) тиешле территориядә референдум мәсьәләләре буенча агитация үткәрүнең билгеләнгән тәртибе үтәлешен тикшереп тора;

д) референдумда тавыш бирү өчен бюллетеньнәрне һәм референдум әзерләүгә, уздыруга бәйле башка документларны участок комиссияләренә илтеп тапшыруны оештыра;

е) тиешле территориядә референдум әзерләүгә һәм уздыруга бәйле мәсьәләләр буенча дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлек итә;

ж) федераль законнарда, әлеге Законда, башка законнарда билгеләнгән бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.»;

5) 19 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19 статья. **Участок комиссияләренең вәкаләтләре**

Референдум әзерләгәндә һәм уздырганда участок комиссиясе:

а) участок комиссиясенең адресы һәм телефон номеры турында, аның эш вакыты, шулай ук тавыш бирү көне, вакыты һәм урыны турында халыкка мәгълүмат бирә;

б) референдумда катнашучыларның исемлеген төгәлләштерә, референдумда катнашучыларны шушы исемлек белән таныштыра, әлеге исемлектәге хаталар һәм төгәлсезлекләр турында гаризаларны карый һәм аңа тиешле үзгәрешләр кертү хакындагы мәсьәләләрне хәл итә;

в) тавыш бирү өчен биналар, тавыш бирү әрҗәләрен һәм башка җиһазлар әзерләүне тәэмин итә;

г) югарырак референдум комиссиясеннән алынган белешмәләр нигезендә референдумда катнашучыларга референдум мәсьәләләре турында мәгълүмат бирүне тәэмин итә;

д) референдум участогы территориясендә референдум мәсьәләләре буенча агитация үткәрү тәртибенең үтәлешен тикшереп тора;

е) референдумда тавыш бирү өчен башка референдум участогында тавыш бирү таныклыкларын бирә;

ж) тавыш бирү көнендә референдум участогында тавыш бирүне оештыра;

з) тавышлар санауны уздыра, референдум участогында тавыш бирү йомгакларын билгели, тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзи һәм аны территория комиссиясенә тапшыра;

и) референдум участогында тавыш бирү йомгакларын игълан итә һәм тавыш бирү барышын күзәтеп баручы затларга тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең таныкланган күчермәләрен бирә;

к) әлеге Законны, башка законнарны бозуга карата шикаятьләрне (гаризаларны) үз вәкаләтләре чикләрендә карый һәм күрсәтелгән шикаятьләр (гаризалар) буенча дәлилле карарлар кабул итә;

л) референдум әзерләүгә һәм уздыруга бәйле документларны саклауны һәм югарырак референдум комиссиясенә тапшыруны тәэмин итә;

м) әлеге Закон нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.»;

6) 26 статьяда:

а) 11 пунктта «20 көннән» сүзләрен «10 көннән» сүзләренә алмаштырырга;

б) 13 пунктта «20 көндә» сүзләрен «10 көндә» сүзләренә алмаштырырга;

7) 27 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«27 статья. **Референдум участоклары**

1. Тавыш бирүне уздыру һәм референдумда катнашучыларның тавышларын санау өчен Федераль закон, Татарстан Республикасы Сайлау кодексы нигезендә төзелгән бердәй сайлау участоклары, референдум участоклары файдаланыла.

2. Референдумда катнашучылар вакытлыча була торган урыннарда (хастаханәләрдә, шифаханәләрдә, ял йортларында,

вокзалларда, аэропортларда, шик белдерелгән һәм гаепләнүче затларны сак астында тоту урыннарында һәм вакытлыча була торган башка урыннарда) референдум участоклары территория комиссиясе тарафыннан ул билгеләгән срокка тавыш бирү көненә кадәр 45 көннән дә соңга калмыйча, ә аерым очракларда тавыш бирү көненә кадәр өч көннән дә соңга калмыйча төзелергә мөмкин.

3. Референдум участокларының исемлекләре, аларның чикләрен (әгәр референдум участогы торак пункт территориясе өлешендә төзелгән булса) йә торак пунктларның исемлеген (әгәр референдум участогы бер яисә берничә торак пункт территориясендә төзелгән булса) һәм участок комиссияләренең номерларын, урнашкан урыннарын һәм тавыш бирү биналарын күрсәтеп, муниципаль районның, шәһәр округының җирле администрациясе башлыгы тарафыннан тавыш бирү көненә кадәр 40 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарылырга тиеш. Референдумда катнашучылар вакытлыча була торган урыннарда (хастаханәләрдә, шифаханәләрдә, ял йортларында, вокзалларда, аэропортларда, шик белдерелгән һәм гаепләнүче затларны сак астында тоту урыннарында һәм вакытлыча була торган башка урыннарда) төзелгән референдум участоклары турындагы мәгълүмат шушы учреждениеләрнең администрацияләре тарафыннан референдумда катнашучыларга җиткерелә һәм алар төзелгәннән соң ике көннән дә соңга калмыйча территория комиссиясе тарафыннан бастырып чыгарылырга тиеш.»;

8) 37 статьяның 1 пунктында «алар күрсәткән федераль кандидатлар исемлекләренә «Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлаулар турында» Федераль законның $82^1$ статьясы нигезендә депутат мандатлары тапшырылган һәм (яисә) алар күрсәткән кандидатлар исемлекләренә» сүзләрен төшереп калдырырга;

9) 43 статьяда түбәндәге эчтәлекле 9 һәм 10 пунктлар өстәргә:

«9. Референдум уздырганда файдаланыла торган бюллетеньнәр, башка референдум участогында тавыш бирү таныклыклары, махсус билгеләр (маркалар) әзерләүгә заказлар урнаштыру «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законда каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

10. Референдум әзерләүгә һәм уздыруга бәйле товарлар кайтаруга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә заказлар ур-

наштыру комиссияләр тарафыннан тиешле бюджетның расланган бюджет язмасы нигезендә референдум билгеләү турындагы карар рәсми басылып чыккан (бастырып чыгарган) көнгә кадәр гамәлгә ашырылырга мөмкин.»;

10) 44 статьяда:

а) 1 пунктта «референдум билгеләү турындагы карар рәсми басылган көнгә хезмәт өчен түләүнең федераль законда билгеләнгән 20 мең минималь күләменнән» сүзләрен «40 миллион сумнан» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Референдум фонды түбәндәге акчалар исәбеннән төзелергә мөмкин:

а) әлеге Законның 12 статьясындагы 1 пункты нигезендә төзелгән референдум уздыру буенча инициатив төркем әгъзаларының үз акчалары, алар гомумән алганда референдум уздыру буенча инициатив төркемнең һәр әгъзасы өчен референдум фонды акчаларыннан барлык чыгымнарның иң чик суммасыннан бер проценттан арта алмый;

б) сайлау берләшмәләренең, башка иҗтимагый берләшмәләрнең, шул исәптән әлеге Законның 12 статьясындагы 2 пункты нигезендә референдум уздыру инициаторлары булып торучыларның ихтыярый иганәләре, һәр сайлау берләшмәсе, башка иҗтимагый берләшмә өчен референдум фонды акчаларыннан барлык чыгымнарның иң чик суммасыннан 50 проценттан артыграк булмаган күләмдә;

в) гражданнарның һәм юридик затларның ихтыярый иганәләре, һәр граждан, юридик зат өчен референдум фонды акчаларыннан барлык чыгымнарның иң чик суммасыннан тиешенчә бер проценттан һәм җиде проценттан артыграк булмаган күләмдә.»;

11) 45 статьяның 8 пунктындагы «а» – «в» пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) референдум фондыннан акчалар тоту буенча финанс операциясе турында, аның күләме референдум фонды акчаларын тотуның иң чик күләменнән биш проценттан артыграк булган очракта;

б) референдум фонды акчаларын тотуның иң чик күләменнән өч проценттан артыграк суммада референдум фондына иганәләр керткән юридик затлар турында;

в) референдум фонды акчаларын тотуның иң чик күләменнән 0,4 проценттан артыграк суммада референдум фондына иганәләр керткән гражданнар саны турында;»;

12) 48 статьяның 9 пунктында «20 көн» сүзләрен «10 көн» сүзләренә алмаштырырга;

13) 50 статьяда:

а) 2 пунктта «20 көннән» сүзләрен «10 көннән» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 пунктта «тавыш бирү башланыр алдыннан» сүзләрен «тавыш бирү вакыты җитәр алдыннан гына» сүзләренә алмаштырырга, «референдумда катнашучыларга,» сүзләрен төшереп калдырырга, «һәм пломба салына» сүзләрен өстәргә;

в) 14 пунктта икенче җөмләне төшереп калдырырга;

14) 51 статьяның 5 пунктындагы беренче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге статьяның 4 пунктында күрсәтелгән гаризалар (телдән мөрәҗәгатьләр) тавыш бирү көненә кадәр 10 көн эчендә теләсә кайсы вакытта, әмма тавыш бирү вакыты тәмамланырга алты сәгатьтән дә соңга калмыйча тапшырылырга мөмкин.»;

15) 52 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пункт өстәргә:

«$1^1$. Тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмә электрон рәвештә төзелергә мөмкин.»;

б) 2 пунктта:

беренче абзацтагы беренче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә кәгазьдә рәсмиләштерелгән очракта бер биттә төзелергә тиеш.», «и» пунктчасында «участок комиссиясенең мөһере» сүзләреннән соң «(кәгазьдә төзелгән беркетмә өчен)» сүзләрен өстәргә;

16) 53 статьяда:

а) 27 пунктта түбәндәге эчтәлекле яңа икенче һәм өченче җөмләләр өстәргә: «Әгәр беркетмә электрон рәвештә төзелгән булса, аның күчермәсе беркетмәне кәгазьдә чыгарып алу юлы белән әзерләнә һәм Федераль законда билгеләнгән тәртиптә таныклана. Беркетмәләрнең бирелә торган таныкланган күчермәләренә номер сугыла.»;

б) 29 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«29. Тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең икенче нөсхәсе танышу өчен күзәтүчеләргә, әлеге Законның 22 ста-

тьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән башка затларга тапшырыла, ә аның таныкланган күчермәсе гомуми танышу өчен участок комиссиясе билгеләгән урынга элеп куела. Әгәр беркетмә электрон рәвештә төзелгән булса, аның икенче нөсхәсе беркетмәне кәгазьдә чыгарып алу юлы белән әзерләнә һәм тавыш бирү йомгакларын билгеләгәндә һәм беркетмә төзегәндә участок комиссиясенең шунда булган хәлиткеч тавыш хокукына ия барлык әгъзалары тарафыннан имзалана. Беркетмәнең икенче нөсхәсе законда каралган референдум документациясе белән бергә, бюллетеньнәрне, участок комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзаларының, әлеге Законның 22 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән башка затларның исемлекләрен дә кертеп, шулай ук участок комиссиясе мөһере саклау өчен югарырак комиссиягә тапшырыла.».

**3 статья**

«Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (II өлеш); 2005, № 3 (I өлеш); 2008, № 5 (II өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8, № 12) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 18 статьяның 5 пунктындагы икенче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Тавыш бирүне эш көне булмаган бәйрәм көненә, аннан алдагы көнгә, эш көне булмаган бәйрәм көненнән соңгы көнгә һәм билгеләнгән тәртиптә эш көне дип игълан ителгән якшәмбегә билгеләү рөхсәт ителми.»;

2) 19 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Референдум әзерләүне һәм уздыруны түбәндәге референдум комиссияләре башкаралар:

муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе;

участок комиссияләре.»;

3) 20 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20 статья. **Муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе вәкаләтләре**

Референдум әзерләгәндә һәм уздырганда муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе:

а) муниципаль берәмлек территориясендә гражданнарның референдумда катнашу хокукының үтәлешен тикшереп тора;

б) муниципаль берәмлек территориясендә референдум әзерләүгә һәм уздыруга, кирәкле басма продукция чыгаруга бәйле чараларны гамәлгә ашыруны тәэмин итә;

в) түбәнгерәк референдум комиссияләренә хокукый, методик, оештыру-техник ярдәм күрсәтә;

г) инициатив төркемне терки;

д) муниципаль берәмлек территориясендә референдум мәсьәләләре буенча агитация үткәрү өчен инициатив төркем һәм референдумда катнашучыларның башка төркемнәре арасында эфир вакытын һәм матбугат мәйданын бүлүнең бердәм тәртибе үтәлешен тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыра;

е) референдумда тавыш бирү бюллетене рәвешен һәм текстын, шулай ук референдумда катнашучылар исемлегенең һәм референдум әзерләүгә һәм уздыруга бәйле башка документларның рәвешен раслый;

ж) референдумда тавыш бирү өчен башка референдум участогында тавыш бирү таныклыгы рәвешен раслый, референдумда тавыш бирү өчен башка референдум участогында тавыш бирү таныклыкларын әзерләүне тәэмин итә;

з) түбәнгерәк референдум комиссияләре мөһерләренең үрнәкләрен раслый;

и) референдум әзерләүне һәм уздыруны, референдум комиссияләренең эшчәнлеген финанс белән тәэмин итүгә җирле бюджеттан бирелгән акчаларны бүлә, күрсәтелгән акчаларның максатчан кулланылуын тикшереп тора;

к) муниципаль берәмлек территориясендә референдум уздырганда тавыш бирү йомгакларын билгеләүнең, референдум нәтиҗәләрен ачыклауның бердәм тәртибе үтәлешен тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыра;

л) муниципаль берәмлек территориясендә тавыш бирү йомгакларын һәм референдум нәтиҗәләрен бастырып чыгаруның бердәм тәртибе үтәлешен тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыра;

м) референдум әзерләүгә һәм уздыруга бәйле мәсьәләләр буенча җирле үзидарә органнары хәбәрләрен тыңлый;

н) түбәнгерәк референдум комиссияләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләрне (гаризаларны) карый һәм шикаятьләр (гаризалар) буенча дәлилле карарлар кабул итә;

о) референдумда катнашучыларны референдум әзерләү һәм уздыру турындагы мәгълүмат белән тәэмин итә;

п) референдум комиссияләрен биналар, транспорт чаралары һәм элемтә чаралары белән тәэмин итүне тикшереп тора, референдумны матди-техник тәэмин итүнең башка мәсьәләләрен карый;

р) федераль законнарда, әлеге Законда, Татарстан Республикасының башка законнарында, муниципаль берәмлек уставында билгеләнгән бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.»;

4) 21 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«21 статья. **Участок комиссияләренең вәкаләтләре**

Референдум әзерләгәндә һәм уздырганда участок комиссиясе:

а) участок комиссиясенең адресы һәм телефон номеры турында, аның эш вакыты, шулай ук тавыш бирү көне, вакыты һәм урыны турында халыкка мәгълүмат бирә;

б) референдумда катнашучыларның исемлеген төгәлләштерә, референдумда катнашучыларны шушы исемлек белән таныштыра, әлеге исемлектәге хаталар һәм төгәлсезлекләр турында гаризаларны карый һәм аңа тиешле үзгәрешләр кертү хакындагы мәсьәләләрне хәл итә;

в) тавыш бирү өчен биналар, тавыш бирү әрҗәләрен һәм башка җайланмалар әзерләүне тәэмин итә;

г) югарырак референдум комиссиясеннән алынган белешмәләр нигезендә референдумда катнашучыларга референдум мәсьәләләре турында мәгълүмат бирүне тәэмин итә;

д) референдум участогы территориясендә референдум мәсьәләләре буенча агитация үткәрү тәртибенең үтәлешен тикшереп тора;

е) референдумда тавыш бирү өчен башка референдум участогында тавыш бирү таныклыкларын бирә;

ж) тавыш бирү көнендә референдум участогында тавыш бирүне оештыра;

з) тавышлар санауны уздыра, референдум участогында тавыш бирү йомгакларын билгели, тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзи һәм аны муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенә тапшыра;

и) референдум участогында тавыш бирү йомгакларын игълан итә һәм тавыш бирү барышын күзәтеп баручы затларга тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең таныкланган күчермәләрен бирә;

к) әлеге Законны, башка законнарны бозуга карата шикаятьләрне (гаризаларны) үз вәкаләтләре чикләрендә карый

һәм күрсәтелгән шикаятьләр (гаризалар) буенча дәлилле карарлар кабул итә;

л) референдум әзерләүгә һәм уздыруга бәйле документларны саклауны һәм югарырак референдум комиссиясенә тапшыруны тәэмин итә;

м) әлеге Закон нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.»;

5) 27 статьяда:

а) 13 пунктта «20 көндә» сүзләрен «10 көндә» сүзләренә алмаштырырга;

б) 15 пунктта «20 көндә» сүзләрен «10 көндә» сүзләренә алмаштырырга;

6) 28 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«28 статья. **Референдум участоклары**

1. Тавыш бирүне уздыру һәм референдумда катнашучыларның тавышларын санау өчен федераль закон, Татарстан Республикасы Сайлау кодексы нигезендә төзелгән бердәй сайлау участоклары, референдум участоклары файдаланыла.

2. Референдумда катнашучылар вакытлыча була торган урыннарда (хастаханәләрдә, шифаханәләрдә, ял йортларында, вокзалларда, аэропортларда, шик белдерелгән һәм гаепләнүче затларны сак астында тоту урыннарында һәм вакытлыча була торган башка урыннарда) референдум участоклары муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе тарафыннан ул билгеләгән срокка тавыш бирү көненә кадәр 45 көннән дә соңга калмыйча, ә аерым очракларда тавыш бирү көненә кадәр өч көннән дә соңга калмыйча төзелергә мөмкин.

3. Референдум участокларының исемлекләре, аларның чикләрен (әгәр референдум участогы торак пункт территориясе өлешендә төзелгән булса) йә торак пунктларның исемлеген (әгәр референдум участогы бер яисә берничә торак пункт территориясендә төзелгән булса) һәм участок комиссияләренең номерларын, урнашкан урыннарын һәм тавыш бирү биналарын күрсәтеп, муниципаль районның, шәһәр округының җирле администрациясе башлыгы тарафыннан тавыш бирү көненә кадәр 40 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарылырга тиеш. Референдумда катнашучылар вакытлыча була торган урыннарда (хастаханәләрдә, шифаханәләрдә, ял йортларында, вокзалларда, аэропортларда, шик белдерелгән һәм гаепләнүче затларны сак астында тоту урыннарында һәм вакытлыча була торган башка урыннарда) төзелгән референдум участоклары турындагы

мәгълүмат шушы учреждениеләрнең администрацияләре тарафыннан референдумда катнашучыларга җиткерелә һәм алар төзелгәннән соң ике көннән дә соңга калмыйча муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе тарафыннан бастырып чыгарылырга тиеш.»;

7) 39 статьяның 1 пунктында «алар күрсәткән федераль кандидатлар исемлекләренә «Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлаулар турында» Федераль законның 82[1] статьясы нигезендә депутат мандатлары тапшырылган һәм (яисә) алар күрсәткән кандидатлар исемлекләренә» сүзләрен төшереп калдырырга;

8) 45 статьяда түбәндәге эчтәлекле 10 һәм 11 пунктлар өстәргә:

«10. Референдум уздырганда файдаланыла торган бюллетеньнәр, башка референдум участогында тавыш бирү таныклыклары, махсус билгеләр (маркалар) әзерләүгә заказлар урнаштыру «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законда каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

11. Референдум әзерләүгә һәм уздыруга бәйле товарлар кайтаруга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштыру комиссияләр тарафыннан тиешле бюджетның расланган бюджет язмасы нигезендә референдум билгеләү турындагы карар рәсми басылып чыккан (бастырып чыгарган) көнгә кадәр гамәлгә ашырылырга мөмкин.»;

9) 46 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Референдум фонды түбәндәге акчалар исәбеннән төзелергә мөмкин:

а) әлеге Законның 13 статьясындагы 2 пункты нигезендә төзелгән референдум уздыру буенча инициатив төркем әгъзаларының үз акчалары, алар гомумән алганда референдум уздыру буенча инициатив төркемнең һәр әгъзасы өчен референдум фонды акчаларыннан барлык чыгымнарның иң чик суммасыннан бер проценттан арта алмый;

б) сайлау берләшмәләренең, башка иҗтимагый берләшмәләрнең, шул исәптән әлеге Законның 13 статьясындагы 3 пункты нигезендә референдум уздыру инициаторлары булып торучыларның ихтыярый иганәләре, һәр сайлау берләшмәсе, баш-

ка иҗтимагый берләшмә өчен референдум фонды акчаларыннан барлык чыгымнарның иң чик суммасыннан 50 проценттан артыграк булмаган күләмдә;

в) гражданнарның һәм юридик затларның ихтыярый иганәләре, һәр граждан, юридик зат өчен референдум фонды акчаларыннан барлык чыгымнарның иң чик суммасыннан тиешенчә бер проценттан һәм җиде проценттан артыграк булмаган күләмдә.

Референдум фонды акчаларын тотуның иң чик күләме дүрт миллион сумнан артыграк була алмый.»;

10) 47 статьяның 8 пунктындагы «а» – «в» пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) референдум фондыннан акчалар тоту буенча финанс операциясе турында, аның күләме референдум фонды акчаларын тотуның иң чик күләменнән биш проценттан артыграк булган очракта;

б) референдум фонды акчаларын тотуның иң чик күләменнән өч проценттан артыграк суммада референдум фондына иганәләр керткән юридик затлар турында;

в) референдум фонды акчаларын тотуның иң чик күләменнән 0,4 проценттан артыграк суммада референдум фондына иганәләр керткән гражданнар саны турында;»;

11) 50 статьяның 9 пунктында «20 көн» сүзләрен «10 көн» сүзләренә алмаштырырга;

12) 52 статьяда:

а) 2 пунктта «20 көннән» сүзләрен «10 көннән» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 пунктта «тавыш бирү башланыр алдыннан» сүзләрен «тавыш бирү вакыты җитәр алдыннан гына» сүзләренә алмаштырырга, «референдумда катнашучыларга,» сүзләрен төшереп калдырырга, «һәм пломба салына» сүзләрен өстәргә;

в) 14 пунктта икенче җөмләне төшереп калдырырга;

13) 53 статьяның 5 пунктындагы беренче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Әлеге статьяның 4 пунктында күрсәтелгән гаризалар (телдән мөрәҗәгатьләр) тавыш бирү көненә кадәр 10 көн эчендә теләсә кайсы вакытта, әмма тавыш бирү вакыты тәмамланырга алты сәгатьтән дә соңга калмыйча тапшырылырга мөмкин.»;

14) 54 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пункт өстәргә:

«1[1]. Тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә электрон рәвештә төзелергә мөмкин.»;

б) 2 пунктта:

беренче абзацтагы беренче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә кәгазьдә рәсмиләштерелгән очракта бер биттә төзелергә тиеш.», «и» пунктчасында «участок комиссиясенең мөһере» сүзләреннән соң «(кәгазьдә төзелгән беркетмә өчен)» сүзләрен өстәргә;

15) 55 статьяда:

а) 27 пунктта түбәндәге эчтәлекле яңа икенче һәм өченче җөмләләр өстәргә: «Әгәр беркетмә электрон рәвештә төзелгән булса, аның күчермәсе беркетмәне кәгазьдә чыгарып алу юлы белән әзерләнә һәм «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законда билгеләнгән тәртиптә таныклана. Беркетмәләрнең бирелә торган таныкланган күчермәләренә номер сугыла.»;

б) 29 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«29. Тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең икенче нөсхәсе танышу өчен күзәтүчеләргә, әлеге Законның 24 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән башка затларга тапшырыла, ә аның таныкланган күчермәсе гомуми танышу өчен участок комиссиясе билгеләгән урынга элеп куела. Әгәр беркетмә электрон рәвештә төзелгән булса, аның икенче нөсхәсе беркетмәне кәгазьдә чыгарып алу юлы белән әзерләнә һәм тавыш бирү йомгакларын билгеләгәндә һәм беркетмә төзегәндә участок комиссиясенең шунда булган хәлиткеч тавыш хокукына ия барлык әгъзалары тарафыннан имзалана. Беркетмәнең икенче нөсхәсе законда каралган референдум документациясе белән бергә, бюллетеньнәрне, участок комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзаларының, әлеге Законның 24 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән башка затларның исемлекләрен дә кертеп, шулай ук участок комиссиясенең мөһере саклау өчен югарырак комиссиягә тапшырыла.».

**4 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 18 октябре
№ 82-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 1151. «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 26 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 5; 2007, № 2 – 3, № 11; 2010, № 12 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның беренче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында һәр граждан дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм аларның вазыйфаи затларына, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләргә һәм халык өчен әһәмиятле функцияләрне гамәлгә ашыру йөкләнгән башка оешмаларга һәм аларның вазыйфаи затларына (алга таба – органнар һәм вазыйфаи затлар) шәхсән яисә үз вәкиле аша мөрәҗәгать итәргә, шулай ук индивидуаль һәм, гражданнар, шул исәптән юридик затлар берләшмәләренең мөрәҗәгатьләрен дә кертеп, коллектив мөрәҗәгатьләр җибәрергә хокуклы.»;

2) 2 статьяның беренче өлешендә «гражданның мөрәҗәгате» сүзләреннән соң «, гражданнар, шул исәптән юридик затлар берләшмәләренең мөрәҗәгате» сүзләрен өстәргә;

3) 5 статьяның өченче өлешендә «һәм җавап» сүзләрен «яисә җавап» сүзләренә алмаштырырга

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 18 октябре
№ 83-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 1152. «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 24 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 5 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 1), аңа түбәндәге эчтәлекле абзац өстәп, үзгәреш кертергә:

«Вәкаләтле орган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары буенча һәм «Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыручы махсуслаштырылган оешма (коммерция-

чел булмаган республика оешмасы) белән килешү нигезендә соңгысына вәкаләтле орган исеменнән ятим балаларга торак урыннарын фактта бирү һәм алар белән югарыда күрсәтелгән шартнамәләр төзү гамәлләрен башкаруны йөкләргә мөмкин.»

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 28 октябре
№ 84-ТРЗ

# II
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ҺӘМ АНЫҢ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЛАРЫ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1153. Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык бишенче утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы кырык бишенче утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында.

2. Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Яңа Савин суд районы буенча 2 нче суд участогы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкару турында.

3. Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Россия Федерациясендә Татарстан Республикасының Вәкаләтле вәкиле итеп Р.К. Әхмәтшинны билгеләп куюны килештерү турында.

4. «Җирле үзидарә органнарына торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында Татарстан Республикасы аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану хакында» 527-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

5. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 532-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

6. «2014 елга, 2015 һәм 2016 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 530-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

7. «2014 елга, 2015 һәм 2016 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» 531-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

8. «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 494-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (III укылыш).

9. «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы белән үзара эшчәнлеге турында» 497-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (III укылыш).

10. «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» Татарстан Республикасы Законының 14 статьясына үзгәреш кертү хакында» 536-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

11. «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 534-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

12. «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 535-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

13. «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү турында» 541-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

14. «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәреш кертү турында» 529-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

15. «Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» 523-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

16. «Яшь гаиләләргә торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәме күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 538-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

17. «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 539-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

18. «Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 123 статьясына үзгәреш кертү турында» 313495-6 номерлы федераль закон проекты хакында (18 яшькә кадәрге инвалид баласы булган ата-аналарга (опекуннарга, попечительләргә, тәрбиягә бала алган ата-аналарга) үзләренә уңайлы вакытта еллык түләүле отпуск бирү турында).

19. «Сәяси репрессияләр корбаннарын реабилитацияләү турында» Россия Федерациясе Законының 13 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 316538-6 номерлы федераль закон проекты турында (реабилитацияләнгән затларны һәм аларның гаилә әгъзаларын торак урыннар белән тәэмин итү хакындагы норманы төгәлләштерү).

20. «Бөек Ватан сугышы балалары статусы турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча халык депутатларының Орел өлкә Советы закон чыгару инициативасы хакында.

21. «Күңел ачу хезмәтләре күрсәтелгәндә музыкаль әсәрләр башкаручыларның фонограмма куллануы турында кулланучыларга хәбәр итүне тәэмин итү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 299577-6 номерлы федераль закон проекты хакында.

22. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына һәм «Россия Федерациясендә гражданнар сәламәтлеген саклау нигезләре турында» Федераль законның 56 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 318821-6 номерлы федераль закон проекты турында (йөклелекне ясалма өзүне законсыз башкарган өчен административ җаваплылык билгеләү хакында).

23. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 12.17 статьясына үзгәреш кертү хакында» 331843-6 номерлы федераль закон проекты турында (маршрут транспорт чаралары полосасыннан төнлә барлык транспорт чараларының хәрәкәт итүенә хокук билгеләү хакында).

24. «Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының хокукый хәле турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» 333549-6 номерлы федераль закон проекты турында (Россия Федерациясенә виза алу таләп ителмәгән тәртиптә килгән

чит ил гражданнарының Россия Федерациясендә хезмәт эшчәнлегенә рөхсәт алуның махсус тәртибен бетерү максатларында).

25. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 18.8, 18.10 статьяларына һәм 18.11 статьясының 1 өлешенә үзгәрешләр кертү хакында» 336606-6 номерлы федераль закон проекты турында (Россия Федерациясендә тору һәм хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру кагыйдәләрен үтәмәүгә бәйле аерым административ хокук бозулар кылган чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны Россия Федерациясеннән читкә мәҗбүри административ чыгарып җибәрү өлешендә).

26. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 4 бүлегенә үзгәрешләр кертү хакында» 338415-6 номерлы федераль закон проекты турында (административ җаваплылыкны йомшарта торган хәлләрне төгәлләштерү хакында).

27. «Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының хокукый хәле турында» Федераль законның 13 статьясына һәм Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 18.10 һәм 18.15 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 338968-6 номерлы федераль закон проекты турында (Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының аларга эшләү өчен бирелгән рөхсәтләрдә күрсәтелгән эшчәнлек төре буенча гына хезмәт эшчәнлеген башкара алуы хакында, шулай ук әлеге кагыйдә Россия эш бирүчеләре яисә эшләр (хезмәтләр күрсәтү) заказчылары йә чит ил эшчеләре тарафыннан бозылган очракта административ җаваплылык турында).

28. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 339371-6 номерлы федераль закон проекты хакында (чит ил гражданнарының һәм гражданлыгы булмаган затларның Россия Федерациясендә торуына бәйле аерым мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салуны төгәлләштерү турында).

29. «Полиция турында» Федераль законның 12 статьясына үзгәреш кертү хакында» 343515-6 номерлы федераль закон проекты турында (полициягә ягулык-энергетика комплексы объектларының иминлеген тәэмин итүне контрольдә тотуны гамәлгә ашыру бурычын йөкләү өлешендә).

30. Россия Федерациясе Конституциясенә «Россия Федерациясе Югары Суды һәм Россия Федерациясе прокуратурасы

турында»гы төзәтмә хакында 352924-6 номерлы Россия Федерациясе законы проекты турында.

31. «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законының 34 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 348208-6 номерлы федераль закон проекты турында (файдалы казылмалар ятмаларын ачкан өчен дәүләт акчалата түләвенә хокук турында).

32. «Федераль дәүләт урман күзәтчелеген (урманны саклауны) гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 349681-6 номерлы федераль закон проекты хакында.

33. «Россия Федерациясе Урман кодексының 72 һәм 79 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 340551-6 номерлы федераль закон проекты турында (урман кишәрлеген арендалау шартнамәсен өзү өчен өстәмә нигезләр һәм аукционда катнаштырудан баш тарту өчен нигезләр билгеләү өлешендә).

34. «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр әйләнеше турында» Федераль законның $12^1$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 339951-6 номерлы федераль закон проекты турында (Россия Федерациясе Граждан кодексына туры китерү өлешендә).

35. «Россия Федерациясе Тимер юл транспорты уставы» Федераль законына һәм «Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 319967-6 номерлы федераль закон проекты турында (йөксез хәрәкәт составын йөртү тәртибен, йөксез хәрәкәт составының тимер юл транспорты инфраструктурасында булу мәсьәләләрен төгәлләштерү турында).

36. «Этил спирты, алкоголь һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт җайга салуы турында һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү хакында» Федераль законның 16 статьясына үзгәреш кертү турында» 343743-6 номерлы федераль закон проекты хакында (алкоголь продукциясен ваклап сату урыннарына өстәмә чикләүләр билгеләү өлешендә).

37. «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» Федераль законның 1 статьясына үзгәреш кертү хакында» 316467-6 номерлы федераль закон проекты турында (опекуннар һәм попечительләр вазыйфаларын үтәүче оешмалар эшчәнлегенә

күзәтчелекне гамәлгә ашырганда тикшерүләрне оештыру һәм үткәрү үзенчәлекләрен тану хакында).

38. «Берләштерелгән финанс хисаплылыгы турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 349695-6 номерлы федераль закон проекты турында (Россия оешмалары тарафыннан Финанс хисаплылыгының халыкара стандартларын куллануны киңәйтү өлешендә).

39. «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешенә үзгәрешләр кертү турында (салымны җайга салу үзенчәлекләрен билгеләү вәкаләтләре өлешендә)» 344708-6 номерлы федераль закон проекты хакында.

40. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 339803-6 номерлы федераль закон проекты турында (пассажирлар йөртү һәм багаж ташу тарифларын билгеләү вәкаләтләре, җәмәгать фикер алышуы институтын кертү, депутат вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату очрагын билгеләү, шулай ук аерым нигезләмәләрне төгәлләштерү өлешендә).

41. «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларына һәм референдумда катнашу хокукына төп гарантияләр турында» Федераль законның 33 һәм 38 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча халык депутатларының Орел өлкә Советы закон чыгару инициативасы турында.

42. Төрлесеннән

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 24 октябре
№ 3127-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 1154. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 75 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары итеп биш елга түбәндәгеләрне сайларга:

Татарстан Республикасы Алабуга суд районы буенча:
4 нче суд участогына – Рәхимов Ринат Ярославовичны;

Татарстан Республикасы Сарман суд районы буенча:
1 нче суд участогына – Исмәгыйлев Айрат Тәлгать улын;
2 нче суд участогына – Юнысов Илнур Илдус улын;

Татарстан Республикасы Тукай суд районы буенча:
2 нче суд участогына – Дарьина Светлана Сиреновнаны.

2. Әлеге карарның 1 пункты нигезендә сайланган Дарьина Светлана Сиреновнаның Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы вәкаләте чоры күрсәтелгән Татарстан Республикасы җәмәгать судьясының моннан алдагы вәкаләтләр чоры тәмамланган көннән башлана.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 24 октябре
№ 3128-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 1155. Татарстан Республикасы Казан шәһәре Яңа Савин суд районы буенча 2 нче суд участогы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкару турында

«Россия Федерациясендә судьялар статусы турында» Россия Федерациясе Законының $7^1$ статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Яңа Савин суд районы буенча 2 нче суд участогы җәмәгать судьясы вазый-

фаларын бер елга башкаруга отставкадагы судья Камалиева Илсөяр Мирсалих кызын җәлеп итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 24 октябре
№ 3129-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 1156. Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Россия Федерациясендә Татарстан Республикасының Вәкаләтле вәкиле итеп Р.К. Әхмәтшинны билгеләп куюны килештерү турында

